ЯЗЫЛМАГАН ХАТЛАР

Татарстанда почта бүлекләре ябылганга кем гаепле?

> 15

БАРЫСЫ ДА ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

Редакциянең «Туган тел» клубында яшьләр һәм милли мохит турында сөйләштек

> 16–17

МӘКТӘП ХӨКЕМЕ

Махсус комиссия төзеп, укытучының хокукларын якларга, абруен күтәрергә җыеналар

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 169 (29136) | Җомга | 17 ноябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

russianhighways.ru

ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

МӘСКӘҮ БЕЛӘН КАЗАННЫ ЯКЫНАЙТУЧЫ М12 ТРАССАСЫ ДЕКАБРЬДӘ ТУЛЫСЫНЧА АЧЫЛА

6,5 сәгать. Тиздән Казаннан Мәскәүгә машинада барып җитү өчен әнә шул кадәр вакыт үтәчәк. Хәзергә икеләтә күбрәк вакыт кирәк. М12 «Көнчыгыш» тиз йөрешле трассасы бу елның декабрендә үк ачылыр дип көтелә. 15 ноябрьдә олы юлның Чабаксар һәм Татарстанга туры килгән бер өлешен кулланышка тапшырдылар. Тантаналы чарада видеоэлемтә аша Россия Премьер-министры Михаил Мишустин катнашты. Төзелеш эшләре тәгәлләнеп килүче яңа юлдан «ВТ» хәбәрчесе дә йөреп кайтты.

> 5

Ишетми калмагыз

Бәлеш, өчпочмак һәм кыстыбый. Татарстанда яшәүчеләр туристларга һәм, гомумән, республика белән кызыксынучыларга әнә шуларны татып карарга тәкъдим итә. «Промрейтинг» агентлыгы үткәргән тикшеренү нәтиҗәсе бу.
Кунаклар сыйланырга тиешле ризыклар арасында беренче урынны бәлеш алган. Аны сораштыруда катнашучыларның 64,7 проценты тәкъдим иткән. Иң еш телгә алынган биш ризык арасына өчпочмак (62,2%), кыстыбый (58,7%), чәкчәк (54,2%) һәм токмачлы аш та (53,6%) кергән.

Алимент түләмәүчеләр арасында Сукояр, Игезәк һәм Кысла йолдызлыгы астында туганнар күбрәк. Кытай гороскобы буенча исә иң җавапсызлар – Эт, Дуңгыз һәм Куян елында туган кешеләр. Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсендә әнә шундый нәтиҗә чыгарганнар. «Алимент түләмәүченең яшен ачыклаган идек инде. Болар – 35тән 42 яшькә кадәрге ир-атлар. Быел исә мондыйларны яхшылабрак өйрәнәсе иттек. Кияүгә чыгып, бала табарга ниятләүче туташларга безнең мәгълүматларны истә тотарга киңәш итәм», – диде Татарстанның баш суд приставы Әнвәр Закиров Төбәк белән идарә итү үзәгендә (ЦУР) узган эфирда.

Соңгы 3 елда яңа төзелгән йортларда фатир бәясе ике тапкыр диярлек арткан. Үзәк банк рәисе Эльвира Нәбиуллина әйтүенчә, шул өч ел эчендә хезмәт хакы үсүдән ике тапкыр зуррак күрсәткеч бу. Ул ел башыннан бирле халыкка бирелгән кредит күләменең 32 процентка артканлыгын әйтте. Торак бәясе үсү һәм бурычлары зур булган кешеләргә ипотека кредитлары бирү Үзәк банктагыларны да борчый. «Мондый хәл киләчәктә банклар өчен дә, ә иң мөһиме – кредит алучыларның үзләре өчен дә зур кыенлык китереп чыгарырга мөмкин», – ди Эльвира Нәбиуллина. Сүз уңаеннан, октябрь аенда Татарстанда торак сату-алу буенча 11,4 мең килешү төзелгән.

Ноябрь өчен гадәти булмаган җылы көннәр тәмамланып килә. Якын араларда республикада кышкы һава торышы урнашачак.
Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, ялларда – 18, 19 ноябрьдә явым-төшем ихтималы аз. Шул ук вакытта һава температурасы сизелерлек төшәчәк. Көндез –1...–6, төнлә –4...–10 градус салкын көтелә. Юлларда – бозлавык. Синоптиклар фаразына караганда, дүшәмбе – 20 ноябрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы –16 градуска кадәр төшәчәк. Төнлә –5...–10 градус. Дүшәмбе – 20 ноябрьдә кичен һәм сишәмбе – 21 ноябрьдә һава торышы бозылачак: карлы яңгыр, буран көтелә.

Районнарда ни хәлләр?

Менделеевск

Район үзәгендә капиталь төзекләндерүдән соң «Мирас» гимназиясе ачылды. Тантанада Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов һәм район башлыгы Радмир Беляев катнашты. Башта гимназия бинасы 1987 елда балалар бакчасы буларак проектлана һәм төзелә, соңрак, 1993 елда, ул татар гимназиясе статусын ала. Бүген гимназиядә 170 бала белем ала, аларның тугызы – беренче сыйныф укучылары. Уку йорты 264 балага исәпләнгән. Гимназияне ачу яңа эш урыннары булдырачак, учреждение штатында 20 педагогбелгеч эшләячәк. Биредә «Җомга мәктәбе» һәм «Габдулла Тукай әдәби мәктәбе» кебек өстәмә дәресләр үткәрү каралган.
(«Менделеевск яңалыклары»)

Әлмәт

Нефть сәнәгате ветераны Нурсинә Сөләйманова 105 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Аны котларга район башлыгы урынбасары, социаль яклау хезмәте вәкилләре килде. Юбилярга Россия Президенты Владимир Путин һәм Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның котлау телеграммаларын тапшырдылар. Нурсинә Сөләйманова – Әлмәт районында иң өлкән хатын-кыз. Хәзерге вакытта районда яше 100дән арткан 10 кеше яши.
(«Әлмәт таңнары»)

Яшел Үзән

Район үзәк хастаханәсе баш табибы Рамил Мөхәммәтдинов соңгы берничә айда эшкә килгән яшь белгечләр белән очрашты. Исемлектә хирург, терапевт, онколог, стоматолог һәм башка күп кенә белгечләр бар. Ун табиб Казан шәһәренең 7 нче номерлы шәһәр клиник хастаханәсе ординатурасын тәмамлаган. Ел башыннан үзәк хастаханәләрнең төрле бүлекчәләренә 50 табиб эшкә урнашкан. Киткән 30 кешенең күбесе – пенсиягә чыгучылар. Район үзәк хастаханәсендәге барлык яшь табибларга остазлар беркетелгән. Кайберәүләрнең торак мәсьәләләре хәл ителгән, шул исәптән торак арендасын компенсацияләү мәсьәләсе дә хәл ителә. Моннан тыш, алар өчен торак шартларын яхшырту буенча программа да бар.
(«Яшел Үзән»)

Балтач

Салавыч Сәрдегәне авылында яңартылган мәчет ачу тантанасы узды. Авыл халкының сөенечен уртаклашырга Татарстан Диния нәзарәте вәкилләре, район җитәкчелеге килде. Гыйбадәт йорты 1995–1996 елларда төзелгән. 2021–2023 елларда мәчетне яңарту һәм төзекләндерү эшләре алып барылды. Авыл кечкенә булуга да карамастан (70ләп хуҗалык бар), ел әйләнәсе биш вакыт намазга дистәгә якын кеше йөри. Рамазан аенда ифтарлар үткәрелә.
(Диния нәзарәте матбугат хезмәте)

ЙӨЗ ДУСТЫҢ БУЛГАНЧЫ...

Оча торган машина, медицина өлкәсендәге яңалыклар, нигезендә ясалма акыл яткан эшләнмәләр, IT өлкәсендәге казанышлар. Ерактагы киләчәктер бу, дип аптырыйсы түгел. Кытайдагы Шэньчжэнь каласында узган югары технологияләр күргәзмәсендә әнә шундый чынбарлыкны күрсәттеләр. Ерактагы якын дусларныңниләр белән шөгыльләнүләрен Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та күреп кайтты.

tatarstan.ru

Шэньчжэньне, уены-чыны бергә, Азиянең булачак башкаласы, инновацияләр каласы, киләчәк шәһәре, дип тә йөртәләр. Кытай югары технологияләр күргәзмәсенең бирелдә узуы да мантыйкка туры килә, димәк. Ел саен бу чарада 1 меңләп компания, 500 меңләп кеше катнаша.

Татарстан делегациясе дә күргәзмәдә тәкъдим ителгән эшләнмәләр белән танышты. Аерым алганда, бу – микросхема, чип, программа тәэминаты (ПО) җитештерүчеләр стенды, Кытай галимнәренең медицина өлкәсендәге тәҗрибәсе. Моннан тыш Рәис стартапларга инвестиция кертүче компания эшчәнлеге белән дә танышты. Бу оешма 85 фонд белән хезмәттәшлек итә. Чит ил компанияләренә дә булыша. Рөстәм Миңнеханов алар тәҗрибәсен безнекеләргә дә өйрәнергә кушты.

Күргәзмәдән соң Рөстәм Миңнеханов Шэньчжэнь шәһәренең вице-мэры Ван Шоужуй белән очрашты. Очрашуда хезмәттәшлекне арттыру турында сөйләштеләр.

Кытайның күптәнге якын дусты. Шэньчжэнь шәһәре вице-мэры Татарстан делегациясен әнә шундый сүзләр белән сәламләде. Йөз дустың булганчы, бер Татарстан булсын шул.

– Кытай югары технологияләр күргәзмәсендә катнашуыгыз өчен рәхмәт. Хезмәттәшлекнең шундый нигезе бәрабәренә без мөнәсәбәтләребезне тагын да ныгытырбыз дип ышанам. Татарстан – бик матур төбәк. Безне ныклы дуслык якынайта, – диде Ван Шоужуй.

Рөстәм Миңнеханов та Шэньчжэнь каласыннан республика үзенә күп нәрсә алды һәм киләчәктә дә алыр дип өметләнә.

– Шэньчжэнь белән Универсиаданы үткәрү хокукы өчен көрәшкәндә, җиңү өчен безгә нибары 1 тавыш җитмәде. Лаеклы булсак та, сез безне җиңдегез. Сездән без күпкә өйрәндек, аерым алганда, зур спорт чараларын уздыруда тәҗрибәгездән файдаландык. Сез безнең өчен университет сыман булдыгыз, – диде Татарстан Рәисе.

Рөстәм Миңнеханов шәһәр җитәкчелеге белән очрашудан соң Шэньчжэньдәге кайбер предприятиеләрне дә карады. Аерым алганда, болар – генератор һәм электр-химия җиһазларын җыя торган завод, автомобиль, электроника һәм аккумуляторлар җитештерә торган компания. Беренчесендә республика җитәкчесенә йөк машиналары һәм водородта йөри торган автобусларны ничек ясаулары турында сөйләделәр. Татарстан Рәисе бу өлкәдә дә хезмәттәшлекне арттырып булуына өметләнүен әйтте.

Сүз уңаеннан, былтыр Татарстан белән Кытай арасында товар әйләнеше 1,6 млрд долларга җиткән (+58%) иде. Быелның ярты елында гына да товар әйләнеше 1,5 млрд доллардан артып киткән инде.

Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин дәүләт ветеринария оешмаларына «LADA Niva Travel» машинасы ачкычларын тапшырды. Шулай итеп, республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов карары буенча төрле районнарның ветеринарларына 30 машина кайта. «Бу машиналар тиз арада ветеринария ярдәме күрсәтергә, чирләрне булдырмый калырга ярдәм итәчәк», – диде Хөкүмәт башлыгы Казанда узган тантанада. Алексей Песошин әйтүенчә, авыл хуҗалыгының (ә ветеринария хезмәте аның мөһим өлеше булып тора) әйбәт эшләве республикага Россиянең төп төбәкләреннән берсе булып калу мөмкинлеге бирә.

Күбрәк түлисе

Киләсе елның гыйнварыннан республикада капиталь ремонт өчен түләү күләме артачак. Бу хакта Татарстан төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгының беренче урынбасары Алексей Фролов әйтте.

Быел 1 кв. метр өчен минималь түләү күләме 6 сум 95 тиен тәшкил итә. Киләсе ике атна эчендә бу сумманың күпмегә артасы билгеле булачак. Ул 7 сумнан да ким булмас дип фаразлыйлар.

Киләсе елда Татарстанда капиталь ремонт программасына 672 күпфатирлы йорт керер дип фаразлана. Бу эшне башкарып чыгу өчен 6,911 млрд сум акча тотылачак. Быелгы эшләрнең 99,9 проценты инде башкарылган. «Быел программага 740 йорт керде. 4 объектны тәмамлыйсы калды. Бу йортларда да эш ахырына якынлаша», – диде Алексей Фролов. Программаны тормышка ашыру өчен 6,65 млрд сум акча тотылган.

2008 елдан бирле Татарстанда күпфатирлы йортларда капиталь ремонт ясау өчен 90 млрд сумга якын акча тотылган. Шуның яртысына якыны – халыктан җыелган акча. Бу эш 11,5 мең йортта башкарылган.

АЕРЫМ ИГЪТИБАР

«Татар-информ»

Татарстанда махсус хәрби операциядә катнашкан егетләргә барлык төр медицина ярдәме тиешле дәрәҗәдә күрсәтелә. Егетләрнең психологик саулыгын да кайгырталар. Бүген шул максаттан республикада 70 психологик ярдәм кабинеты эшли.

Татарстан сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков сүзләренә караганда, республиканың дәвалау оешмаларында махсус хәрби операциядә контракт буенча хезмәт итеп кайткан егетләргә, ветераннарга хезмәт күрсәтәләр. Хәзерге вакытта МХОда булган егетләр исә, нигездә, Оборона министрлыгына караган госпиталь һәм дәвалау оешмаларына мөрәҗәгать итә. Хәзерге вакытта Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә хәрби хәрәкәт ветераннары госпитальләре эшләп килә. Узган ел исә башкалада хәрби госпиталь ачылды.

– Дөрес, хәзерге вакытта махсус хәрби операциядә булган егетләргә гадәти дәвалау оешмаларында да тиз арада ярдәм күрсәтеләчәк. Аларга һәм гаиләләренә аерым игътибар бирелә, – дип ачыклык кертте Жаворонков.

Махсус хәрби операциядән кайткан егеткә ашыгыч ярдәм кирәк булса, ул тиз арада үзе яшәгән җирлектәге хастаханәгә мөрәҗәгать итә. Тагын да җентеклерәк тикшерү узар өчен, ул республика дәрәҗәсендәге дәвалау оешмаларына җибәреләчәк.

Владимир Жаворонков сүзләренә караганда, Татарстанда махсус хәрби операциядә яраланучыларга протез бирүдә дә тоткарлыклар юк. Егетләргә мондый ярдәмне хәрби госпитальләрдә дә, гадәти дәвалау оешмаларында да күрсәтәләр.

Яшерен-батырын түгел: махсус хәрби операциядә катнашкан егетләр психологик ярдәмгә дә мохтаҗ. 1 июльдән Татарстанда МХОда катнашучыларга ярдәм күрсәтүче 70 психологик консультация бирү кабинеты эшли башлады. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш психиатры Татьяна Гурьянова сүзләренә караганда, бүген хәтта иң кечкенә районда да шундый бүлек эшли.

Татьяна Гурьянова сүзләренә караганда, күпләр, психологка мөрәҗәгать итсәм, исәпкә куярлар дип курка, шуңа күрә белгечкә ярдәм сорап баруны да кичектереп тора. Алдан ук искәртеп куйды ул: әлеге кабинетларда егетләргә фәкать психологик ярдәм генә күрсәтеләчәк. Махсус хәрби операциядә катнашкан кеше начар йокласа, беркем белән дә аралашмыйча, үз эченә бикләнсә, эчүгә сабышса, кичекмәстән психолог, психиатрга мөрәҗәгать итәргә кирәк, ди белгечләр.

Сүз уңаеннан, күптән түгел Татарстанда «Үзебезнекеләрне кайгыртып» дип исемләнгән программа нигезендә махсус сайт (zabotasvo.tatar) һәм «Телеграм»да чат-бот эшли башлады. Бирегә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләренә тиешле барлык ярдәм чаралары турында тулы мәгълүмат тупланган. Шунда ук борчыган сорауларны да җиткерергә мөмкин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ХАТАЛАР ӨСТЕНДӘ ЭШ

ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫКЛАРЫНДА НИНДИ ХОКУК БОЗУЛАР БАР?

«Иң яхшысы – балаларга» дигәндә, кайбер ата-аналар арттырып җибәрә. Кара диңгез буенда ял итсен дип, ялган диплом-грамота, рәхмәт хатларына кадәр сатып ала хәтта. Ришвәтчелек тамыры сәламәтлек саклау тармагына да җәелгән. Халык арасында узган сораштырудан шундый нәтиҗә чыгарганнар.

Ике тармак – Яшьләр эшләре һәм Сәламәтлек саклау министрлыгы җитәкчелеге коррупция очракларын ничек булдырмауларын, булганнарына ничек каршы торуларын сөйләде.

Кырын эшләрне ачыклап, хисап тотулар ел да уза. Татарстан Рәисенең Ришвәтчелеккә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарә җитәкчесе урынбасары Рөстәм Гаязов әйтүенчә, махсус комиссия ел да төрле районнарда булып, төрле тармакларны тикшерә.

– Медицина ягыннан караганда, районнарда проблемалар бер төрле. Әйтик, ОМС акчасын үзләштерү, бушлай булырга тиешле хезмәтләр өчен акча алу, пациентларны кабул итү, электрон чират мәсьәләләре, – диде ул.

Әмма алар бу тикшерүдән соң кемгәдер җәза бирми. Рөстәм Гаязов әйтүенчә, максатлары – киңәш биреп, хатаны төзәтергә булышу. Ягъни тиешле җәзасын урында бирәләр. Эштән алалармы, штраф салалармы – законда ни язылган инде.

Рөстәм Гаязов сүзләренчә, тагын бер авырткан җир булып, максатчан уку программасы тора. Кадрлар кытлыгын аз гына булса да киметә торган бу юнәлештә дә җитешсезлекләр юк түгел.

– Булачак табибларны кайбер учреждениеләр, укып бетергәч, кире кайтыр дип, укырга җибәрә. Әмма кайбер җирлекләргә алар кайтып та тормый. Кайбер районнарда кемнәрне максатчан укытулары турында хәтта белмиләр дә, – диде Рөстәм Гаязов.

Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марсель Миңнуллин исә ришвәтчелек очракларын булдырмас өчен нинди эшләр башкарганнарын санап чыкты. Әллә ни ачыш ясамады үзе. Барысы да гадәти: профилактик чаралар үткәрәләр, сөйләшүләр уздыралар, ришвәт очраклары турында хәбәр итү өчен хастаханәләрдә махсус тартмалар куялар.

Рөстәм Гаязов билгеләп үткәнчә, хокук бозу очраклары күбрәк балалар ялын оештыру юнәлешендә күренә. Иң еш очрый торганнары: ялган документлар тутырып, юк баланы бар итеп күрсәтеп, акча үзләштерү, өстәмә ставка язып, эшләмәгән эш өчен акча алу, ялган рәхмәт хатлары, грамоталар белән баланы Кара диңгез буендагы ял итү лагерьларына җибәрергә тырышу.

Әмма Рөстәм Гаязов министрлык эшенә хәерхаһлы булып чыкты. «Әйе, балаларның ялын оештыруда һәм ведомство карамагындагы учреждениеләрдә җитди кимчелекләр булды. Әмма министрлык алга таба мондый хәл килеп чыкмасын өчен чаралар күрде», – диде ул. Хаталар өстендә эш башкарганнар, кыскасы.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Күзгә күренмәс кеше

Үзенә рәхәт чакта, гадәттә, кеше мине күрми. Исәнләшә, сөйләшә, күрешә, күземә карый, тик күрми. Мин бәлки берәр мебель яки аның тормышын бизәр өчен ясалган декорация сыман тоеламдыр. Әйтә алмыйм. Ләкин күрмәгәнен сизеп торам, чөнки ул минем аша узарга да, түбәнгәрәк төшсәм, таптап китәргә дә әзер. Ишетми дә. Мин аңа нәрсәдер әйтәм – ул ишетми.

Кеше, дигәндә, мин джунглида яшәгәннәрне әйтмим инде, үз тирәмдәгеләрне күз уңында тотам. Кеше мине күрми. Ишетми. Кешегә минсез дә рәхәт. Аннан соң, тирә-юньдәгеләр бер мин генә түгел, араларында күпкә ару сыманнары да җитәрлек. Ару адәмнәр күп... Кеше шуларны күрә, шулар белән аралаша. Аларның файдасын күрә, үзе файда итә. Бер-берсен кулланалар, кыскасы. Һәм кеше шулар белән бергә яшибез, дип уйлый.

Ләкин теге кешенең хәле мөшкелләнеп, башы түбән иелдеме, шул ару адәмнәрнең барысы да диярлек качып бетә. Начар булган өчен түгел, әлбәттә. Менә син көн дә иртән бер чынаякны кулланасың. Әгәр бер иртәдә ул чынаяк кителә икән, аны читкә этеп куясың да икенчесен аласың. Монда да – шул ук хәл.

Аның янында бер мин генә калам. Ни өчен икәнен белмим. Якыннар бит инде без, ни әйтсәң дә. «Таныш» кына дисәң, җитми кала, «туган» дисәң, артып китәр кебек... «Җирдәш» буламы соң...

Башта бик сәерсенеп кенә баштанаяк күз йөгертеп чыга. Бу нишләп монда, ярдәм-фәләнгә мохтаҗ булып, кача алмыйча калган берәр гарип җан түгелме, дип уйлый бугай. Бәлки алай түгелдер. Авыр хәлгә төшкәч, үч алырга килгән дошманы түгелме, дип шөбһәләнүе дә бар. Нәрсә уйлаганы ишетелми, шулай да шикләнү катыш гаҗәпләнү хисе бөтен кыяфәтен томалый.

Начарлык кылырга җыенмавымны сизенгәч, тынычлана төшә. Башта акрын гына йөзе ачыла, аннан – авызы. Белмим, бәлки, ул үзенең тома ялгыз калуына һәм беркемгә кирәксезлегенә төшенеп беткәндер. Ялгызлыгы белән килешкәндер. Һәм менә кинәт... Мин... Ул, әлбәттә, беркадәр аптырап кала... Ул үзе белән бергә яшәп, авыр чакта ташлап качкан теге кешеләрне гаепләми. Ул аларны аңлый. Чөнки үзе дә нәкъ шулар шикелле үк эз суытыр иде. Ә мине аңлый алмый. Кем бу? Ни өчен?

Һәм хәтерли... Теге вакытта мебель кебек тоелган нәрсә... Теге вакытта юк кебек тоелган нәрсә чынбарлык булган бит... Һәм ул менә бу зат булган. Һәм ул кеше булган. Ке-ше... Карале, нужәли шундый кеше була ала? Нужәли кеше шундый була ала? Аның күзләренә яшьләр килә. Шушы кеше өчен ул үзенең бар мөлкәтен, бар дәүләтен, малын, хәтта җанын да бүлми бирергә әзер булыр иде. Ләкин аннан сорап килмәгән бу. Тәкъдим итеп килгән. Ярдәм тәкъдим итеп. Җанын дип тә була. Һәрбер ярдәм – җанның бер өлеше. Коточкыч бит!

Көтмәгәндә килгән матурлык һәрвакыт коточкыч була. Мин – матурлык. Мин бар. Мин коткарам.

Мин аны җитәкләп алам да авыр халәтеннән яктылыкка алып чыгам. Ул яңадан тернәкләнеп китә. Эшен башлый. Дуслары-танышлары табыла. Үз тормышы кабат үзенә кайта. Һәм ул мине оныта. Күрми башлый. Ишетми дә.

Кешене күрә алмас дәрәҗәгә җиткереп, тормыш аның күзен каплый.

Кешеләрдә кешене күрү кирәк. Мин – матурлык. Мин кешедә яшим.

Әйтеп кенә бактым

Спасибо, яме!

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Сеңлем Розаның Балык Бистәсеннән Казанга күчеп килүенә ярты ел да юк әле. Минем кебек бик аралашучан булганга, аз гына вакыт эчендә күпме дуслар тапты, кызыклы кешеләр белән очрашты. Алар турында миңа да сөйләштергәли һәм журналист абыйсына темалар да бүләк итә булып чыга.

Әле күптән түгел генә сеңлем тагын бер кызыклы кеше турында сөйләп алды. Дөресрәге, гыйбрәт итеп язарлык иде ул кеше. Сеңлем Казандагы фатирын, үзе әйтмешли, кеше кыяфәтенә кертеп йөри. Балконына тәрәзәләр куйдырырга бер белгеч чакырган. Ул егет Балык Бистәсенеке булып чыккан, хәтта сеңлем аның әнисе белән таныш та икән. Бер уйлаганда, монысы да кызык. Ә инде әлеге егет сеңлемнең русчасына татарча җавап бирә башлагач, тәмам аптырап калган ул. «Абый, чеп-чи рус егете бернинди акцентсыз татарча сөйләшә бит, егылып китә яздым», – диде.

Икенче көнне иртән шалтыратты сеңлем. «Сөйләшәсең килсә, телефонны аңа бирәм», – диде. Ничек сөйләшмисең ди инде! Шактый гына гәпләшеп алдык. Евгений Макаров атлы икән егетебез. Мин Женя дип сүз башлаган идем, «Татарлар мине Җәүдәт дип йөртә», – дип куймасынмы! Чыннан да, акцент юк иде аның сөйләмендә.

– Җәүдәт дип дәшкәннәренә үпкәләмисеңме соң? – дим.

– Юк. Алар үз итеп, дус итеп әйтә бит.

Женя мәктәптә үк татарча өйрәнә башлаган. Берәү дә мәҗбүр итмәгән аны. «Татар теле сиңа нәрсәгә кирәк соң?» – дип карыйм. «Татарлар арасында дусларым күп бит. Татарча сөйләшсәм, аларның күңелләре була», – ди Женя. Мин һаман төпченәм. Безнең татарлар арасында: «Татар теле белән кая барасың?» – диючеләр барлыгын әйтәм. «Сиңа рус теле җитмәгәнмени?» – дип карыйм. Ә ул ике дә уйламыйча: «Мин бит Татарстанда яшим», – ди. Мондыйрак сүзләрне дә ишеткәнем бар. Әмма алар миңа артык күпшы, хәтта бераз ясалмарак, рәсми рәвештә аклану кебегрәк тә тоелып китә. Ягъни Татарстанда яшәгәч, татарча белми кая барасың, кирәк бит инде. Женяның беркем алдында да патриот булып күренәсе юк. Аның сүзләре ихлас, кылган гамәлләре дә күңел кушуы буенча. Татар телен белүне ул күпмедер дәрәҗәдә мәртәбә дә саный әле. Нәселендә татарлар булмады микән дип шикләнгән дә идем, юк икән. Егетнең гуманитар белеме дә юк. Башта теш ясаучы булырга укыган, тик кеше авызында казынуны яратып бетермәгән, ахрысы, инде менә тәрәзә рамнары ясап, куеп йөри. Шул ук вакытта күп тел белүнең акылга, фикерләү рәвешенә уңай йогынты ясавын да сизенә егет.

Танышларым арасында рус теленә чытырдап ябышып дигәндәй, җәмгыятьтә югарырак урынга үрмәләргә тырышучы татарлар да юк түгел. Алар ана телен белмәүләре белән горурланалар да әле. Алай гына да түгел, ана теленә түбәнсетеп тә карыйлар кебек, дуслары арасында руслар күбрәк булу белән горурланалар, руслар арасында яшәүләре белән мактанып сөйлиләр. Женя-Җәүдәт тә Айда яшәми бит. Әмма ана теленнән ваз кичкәннәрдән акыл дәрәҗәсе белән аерылып тора. Мин ана теленнән ваз кичүне анадан ваз кичүгә тиңлим. Язганнарымны андыйлар укымас. Алар татарча укый-яза белмәүләре белән дә горурланалар. Евгений Макаров белән очраштырасы иде аларны, бәлки «Җәүдәт» сүзенә колак салырлар иде. Монысы аптыраганнан әйтү инде, шулай да на всякий случай Евгенийның телефон номерын алып куйдым әле, чем черт не шутит. Ә сиңа алдан ук зур спасибо, яме, Женя!

БАЛА БӘЯСЕ

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Владимир Путин ана капиталы идеясен күтәреп чыккан һәм аны гамәлгә керткән чакта, 2006 елда, «Кырылыш» дигән язма әзерләгәнмен. Ул вакытта әле мин күпкә яшьрәк һәм рәсми карарларга хәзергегә караганда да ныграк тәнкыйди күз белән караганмын. Унҗиде ел элек матбугатта дөнья күргән язманың төп фикере ана капиталы илдәге демографик вазгыятьне үзгәртмәячәк дигән сүзләргә кайтып калган. Фикерне дәлилләгәнмен инде, билгеле. Шатланып әйтмим, ул фикеремдә ялгышмаганмын.

Ана капиталы 2007 ел башыннан кертелде, нәтиҗәсе булса, ул шунда ук күренә башларга тиеш иде. Әмма нәтиҗә юк. Менә карагыз: «Интерфакс» 2008 елда «Население РФ в 2007 году вновь сократилось» дигән язма биргән. Вазгыять 2011 елда да үзгәрмәгән. «РИА Новости»ның язма исеме дәлилле моны: «Население РФ с начала 2011 г. уменьшилось на 87,5 тыс. человек». Барлык елларның да статистикасын китереп тормыйк, кайбер елларда Россиядә халык саны арткан чаклар да булгалады. Әмма хәзергесе яман. Ана капиталын индексацияләп торуга, аны беренче баладан ук бирүне гамәлгә кертүгә карамастан, илдә кеше саны кискен темплар белән кими. Балалар елдан-ел аз туа, өлкәннәр елдан-ел күбрәк үлә.

Вазгыять бер Россиядә генә түгел, Көнбатышның либераль идеологиясе хөкем сөргән барлык илләрдә дә авыр һәм катлаулы. Россия җитәкчелегендә либеральлектән баш тартып, традицион кыйммәтләргә кайту теләге көчәйде, әмма халык аңында бары тик үзең өчен генә һәм рәхәт чигеп яшәү теләге сүнәрлек түгел. Нәкъ менә шул сәбәпле гаиләләр корылмый, корылганы бик тиз таркала, таркалмаганнарында да бала саны бердән-икедән артмый. Ун гаиләнең җидесе таркала дигән сан күзгә чалынды темага мәгълүмат туплаганда. Гаилә белән яшәү, бигрәк тә балалар табып үстерү – бик мәшәкатьле эш, үз ләззәтләреңне чикләү, фидакарьләрчә башкалар мәнфәгатен кайгыртып яшәүне сорый. Хәзерге массакүләм культура шартларында тәрбияләнгән яшьләр моңа әзер дә түгел, теләмиләр дә. Менә шуларның барысына да матди проблемалар килеп кушыла: торак булмау, очны-очка ялгап яшәү күп бала табып үстерүгә булышмый.

Бүген туксанынчы еллар – ике меңенче еллар башындагы демографик упкынның нәтиҗәләрен тоябыз: ул чор балалары эш яшенә җитте, әмма эшләргә кеше юк. Гаилә корырга һәм балалар табып үстерергә тиешле бик күпләр туксанынчы елларның караңгы вазгыятендә тумый калды. Илнең икътисадый үсешен тупикка китереп тери бу: эшче куллар җитешмәү җитештерүне арттырырга комачаулый. Дәүләт Думасына чакырылгач, депутатларның төп ставканы күтәреп бизнесны акчасыз калдыруда гаепләүләренә җавап итеп, Үзәк банк рәисе Нәбиуллина ханым: «Икътисадның төп проблемасы – акча түгел, эшче куллар җитешмәү», – диде. Финанс регуляторы санаган: 13 мең предприятиедә эшчеләр кытлыгы якадан алган. Проблеманы хәл итү өчен, күпләп мөһаҗирләр китерергә туры килә. Хәзер фермаларда күпчелек таҗиклар, мәсәлән. Мигрантларга гражданлык бирү дә конвейерга куелды, шунсыз мөмкин түгел, күрәсең. Гражданлык алдымы, ил алдында бурычын да үтәргә тиеш бит әле ул. Россиянең милли йөзе үзгәрү ура-патриотларның кытыгына тия. Теманы бу юнәлештә киңәйтеп тормыйк, су асты ташлары күп монда.

Әчке миграция барлыкка килде. Кешеләр хәрби-сәнәгать комплексы үсеш алган зур шәһәрләргә агыла, чөнки оборона тармагында хезмәт хаклары масштаблы үсте. Пропорцияләр шул дәрәҗәгә җитте: җиңел сәнәгать тармагында яисә авыл фермасында, бюджетта эшләп җан асрау кыенлашты. Өч йөз меңне алганнар шундый инфляция бураны кузгалта:

shutterstock.com

утыз меңне алучылар ач паекка кала. Аерым тармакларда хезмәт хакының гипер үсешен эшче куллар муллыгы туктата алыр иде...

Идарәче даирәләр демографик упкынның ни белән янавын аңлый башлады һәм идеяләр парады мәйданга чыкты. Проблеманы чишү өчен, ниләр генә тәкъдим ителми. ВЭБның Тикшеренүләр һәм экспертиза институты белгечләре бизнесны өченче һәм аннан соңгы баласы туган хезмәткәрләргә берәр миллион сум акча түләргә мәҗбүр итәргә дигән фикерне күтәреп чыкты. Искиткеч идея, әмма, гафу итегез, тормышка ашырырлык түгел. Әйтик, иргә дә, хатынга да берәр миллион түләнсә, гаилә матди яктан шактый ук ныгый бит инде. Монысы яхшы. Әмма бизнес андый йөктән котылу өчен күп бала табу перспективасы алдында торган ирләр һәм хатыннардан котылу җаен эзләячәк, бары шул гына. Җитештерүне киңәйтү урынына кысып котылачак проблемадан. Тайвань президентлыгына кандидат Терри Гоу арзанлырак ысул сайлый: яшь әти-әниләргә эт белән мәче бүләк итәргә куша. Аның фикеренчә, бу балалар тууны арттырачак. Дәүләт Думасы депутаты Хәмзәев аборт планлаштырган әниләрнең балаларын хөкүмәтнең сатып алу хокукы булырга тиеш, дигән фикерне алга этәрде. Юк һәм тагын бер тапкыр юк. Сез нәрсә, ана карынын инкубатор, баланы сатып алына торган чебеш дип саныйсызмы әллә? Иң яхшысы: күпләп чебешләр сатып алыгыз да йомырка тавыклару үрчетегез. Алайса илдә йомыркага бәяләр күтәрелә, дип чаң суга чиновниклар.

Идеяләр күп. Бала тапкан өчен бушлай фатир бирүдән алып абортларны тыюга кадәр диапазонда ниләр генә тәкъдим ителми. Үзен генә аерып алып караганда начар түгел алар. Әйтик, өченче баласы туган гаиләнең ипотекасын түләү яисә кулына бушлай фатир ачкычы тоттыруга ничек каршы киләсең? Тормышка ашмаслык ук та түгел. Аның өчен бюджет приоритетларын тамырдан үзгәртергә кирәк. Моңа беркем дә бармаячак. Шундый закон кабул итәргә була, әмма бушлай фатирны күпбалалы гаилә кабер якасына якынлашканда гына күрәчәк. Бездә хәзер дә биш һәм аннан артык балалы гаиләләргә фатир бирү традициясе бетмәде. Алар да еллар буе чират көтә.

Елан озынлыгын попугайларда үлчәргә була, филләрдә дә мөмкин. Ләкин дөрес нәтиҗәгә генә килә алмыйсың. Бала товар түгел, аңа бәһасез кеше итеп карарга кирәк. Карашны, ягъни идеологияне үзгәртми торып, демографик кризис проблемасы чишелми.

ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Өч ел дигәндә

Ил тарихында иң куәтле, иң тиз һәм иң заманча технологияләр ярдәмендә төзелгән юл. М12 югары тизлекле трассасын салу әнә шулай хәтергә кереп калыр, мөгаен. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин әлеге юлны төзи башлау турында 2020 елның 10 июлендә игълан итте. Гомуми озынлыгы 810 чакрым тәшкил иткән трассаны өч ел дигәндә тулысынча куллანышка тапшырырга да җыеналар. Хәзерге вакытта Мәскәүдән Арзамаска кадәр юл ачык. Рәсми мәгълүматларга караганда, М12 тиз йөрешле трассасының бәясе 900 миллиард сумнан артык. Юл түләүле булачак. Эшкә заказ бирүче – «Автодор» дәүләт корпорациясе.

М12 илнең биш төбәген колачлый. Аның 142 чакрымы безнең республикага туры килә. Заманча трасса Татарстанның Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Лаеш һәм Питрәч районнары аша уза. Яңа юлны Мәскәүдән Казанга кадәр ачу тантанасы бу елның декабрь азагына билгеләнгән. Алга китеп булса да әйтик, 2025 елда М12не Төмәнгә кадәр озайту да каралган. Бу атнада исә олы юлның Чабаксар һәм Татарстанга туры килгән бер өлешен, ягъни Шумерля шәһәреннән Р241 Казан – Буа – Ульяновск автомобиль трассасына кадәр 153 чакрым араны кулланышка тапшырдылар.

Иң озын күпер

Замана төзелешен журналистларга да күрсәттеләр. Юл салганны күргән бар ла ул, тик М12 кемне дә шаккатырырлык. Билгеле булганча, югары тизлекле трассаны төзү барышында Идел елгасы аша күпер дә салалар. Биредә эшләр инде беткән диярлек, машина хәрәкәтен декабрьдә ачачаклар. Без килгәндә, төзүчеләр ут баганалары утыртa, тимер коймаларны урнаштыра иде.

– Бу – М12 автомобиль юлында иң озын күпер, әнә шул ягы белән үзенчәлекле, – ди «Дороги и мосты» АҖ проектлар идарәсенең җитештерү хезмәте җитәкчесе Михаил Новоселов. – Һәр якка икешәр полосалы күпернең озынлыгы – 3362 метр. Ул 28 баганада утыра. Терәкләрнең биеклеге 50 метрга җитә. 14 катлы йорт кадәр диган сүз бу. Төзелеш эшләре алдан фаразлаганнан якынча ярты елга тизрәк бара. Моңа, шул исәптән, күперне берьюлы ике ярдан кара-каршы салып килү ярдәм итте. Ярдәмче корылма да төзелде. Аны сүтеп бетердек диярлек инде. Төзелеш эшләре кыш көне дә, җәй көне дә тәүлек әйләнәсе дәвам итте. Күпер салуда 1200 кеше, 200гә якын техника, шул исәптән 13 судно эшләде.

Соңгысын ишеткәч, яңа күпердән барганда Иделдәге утрауларны әрнеп күзәткән каләм әһелләре белгечтән: «Суднолар йөри алдымы соң?» – дип тә кызыксынды. Шөкер, эшкә зыян килмәгән.

Баксаң, илдә соңгы елларда бу кадәр кыска вакыт эчендә мондый зур күпер салганнары булмаган икән. Кырым күперен исәпкә алмаганда, әлбәттә. Төзелешкә металлны илдәге дүрт заводтан, шул исәптән Яшел Үзәндәге металл конструкцияләр заводыннан ташыганнар.

Ә менә күпер тоташкан ярларны кискәннәр. Ничек кенә әле, бу урында юл тоннельне хәтерләтә.

– Күперне юлга тоташтыру өчен, елганың ике ярында 45 метрга кадәр тирәнлектәге уентылар ясалды, – дип сөйләде «Автодор» дәүләт корпорациясенең М12 төзелешенең 8 этабы проекты җитәкчесе Рәшит Хаҗипов. – Иделнең сул як ярыннан – 8, уң як ярыннан 14 миллион куб. метр җир чыгарылды. Ул тулысынча юл төзелешенә тотылды.

Төзүчеләр ике куянның койрыгын берьюлы тота. Тау битләренә ак төстәге төргәкле тукыма (!) җәяләр. Гаҗәпләнмәгез: махсус биоматериал икән бу.

– Биотекстиль тукыма эченә үсемлек орлыклары тегелгән. Бердән, туфрак басылса, икенчедән, орлыклар үсеп чыгып, тамырлары ярдәмендә сөзәклекне яңгыр сулары юудан саклаячак, – дип аңлатты Рәшит Хаҗипов.

Кешеләргә дә, пошиларга да

Машина йөртүче йоклап китеп, хәвефхәтәр килеп чыкмасын өчен, юл сызыкларын махсус кытыршы итеп ясаганнар. Ул тәгәрмәчне тибрәтә икән. М12 трассасында ерак юлга чыгучылар өчен ял мәйданнары да эшләячәк. Татарстанда шундый алты күпфункцияле ял зонасы гамәлдә булачак. Алар юлның ике ягында парлап, Кайбыч районының Олы Кайбыч авылы, Югары Ослан районының Вахит авылы һәм Лаеш районының Егорьево авылы янында урнашачак. Биредә, нинди инвесторлар килүгә карап, ягулык салу станцияләре, кибетләр, сервис үзәкләре, балалар мәйданчыклары, хәтта кунакханәләр булачак, дип сөйләде «Автодор» вәкилләре.

Юл салганда әйләнә-тирә мохит турында да онытмаганнар. Машина каршына поши, кыр кәҗәләре килеп чыкмасын өчен, трассаның буеннан-буена челтәр койма тотылачак. Сукмакларны өзелгән хайваннарга нишләргә, диярсез. Анысын да уйлаганнар. Хайваннар күпләп йөргән урыннарда (мондый миграция сукмаклары белгечләр белән берлектә ачыкланды дип ышандырдылар) кабан дуңгызлары, маралларөчен махсус кичүләр төзегәннәр. Олы юлның Татарстанга туры килә торган өлешендә хайваннар өчен җиде кичү: җир өстеннән – өч, һәм җир астыннан дүрт юл бар. Җир өстеннән уза торган кичү, мәсәлән, экодук дип атала. Ул таш урынына туфрак һәм яшел үлән белән түшәлгән. Агачлар да үсеп утыра.

Гомумән алганда, М12дә якынча биш чакрым саен юл кичүе, юл киселеше, җәяүле юлы кебек ясалма корылма очрый. Машина йөртүчеләр тизлекне киметмәсен өчен, түләүле юл башкалары белән бер яссылыкта кисешми. Акча түләү өчен шлагбаумнар да очрамаячак. Юлдагы рамкалар машинаны үзләре танып белә дә акча машина йөртүченең кесә телефонына урнаштырган махсус кушымта аша үзеннән-үзе алыначак. Акчаны, олы юлдан төшкәч, махсус сайт яки сервис аша да түләргә мөмкин булачак. Казан – Мәскәү арасы якынча 5–6 мең сумга төшәр дип көтелә.

Һавада эшлиләр

Шулай итеп республиканың автомобиль юллары 72 чакрымга артты. Кулланышка тапшырылган яңа юлның шул кадәре Татарстанга туры килә. Биредә генә дә утыздан артык күпер һәм төрле кичүләр төзегәннәр. Алар арасында заманча технологияләр кулланып, Зөя елгасы аша салынган күпер дә бар. Баксаң, мондый корылмалар ил күләмендә дә бармак белән генә санарлык икән.

– Зөя елгасы аша 514 метр озынлыктагы күпер яңа технологияләр кулланып төзелде. Ул чын мәгънәсендә һавада салынды, – ди «Автодор» төзелеш компаниясе генераль директоры урынбасары Илдар Яруллин. – Әлеге технология нигезендә, монолит күперне салу өчен ярдәмче янкормалар төзергә кирәкми. Димәк, чыгымнар кими. Башта терәк багана күтәртелә, әнә шуннан һавада як-якка акрынлап юл салына. Эш барышында гадәттәге кебек бер ай түгел, ә биш тәүлек эчендә ныгый торган бетон катнашмасы файдаланылды.

Төзүчеләр әйтүенчә, әлеге технология безгә Көнбатыштан килгән. Хәзерге вакытта аны тулысынча үзләштергәннәр. Импортны алмаштыру таләп ителми.

– Барлык таләпләр нигезендә мондый күперне салу өчен дүрт ел вакыт кирәк булса, заманча технология ярдәмендә аны ике елда төзеп бетердек. Монолит күпернең ялганган җирләре юк. Яр белән тоташкан урыннардан кала, билгеле. Шуңа күрә ул күпкә чыдамлырак, – ди Илдар Яруллин.

Бу атнада ачылган юлның бер өлеше М12 төзелешенең җиденче этабына (алар барлыгы сигезәү. – **Ред.**) туры килә. «Эш беткәч нишлисез?» – дип тә кызыксындылар юл салучылардан. «Җиңел сулап куячакбыз», – диде «Автодор» дәүләт корпорациясенең М12 төзелешенең 7 этабы проекты җитәкчесе Дмитрий Костин, зур һәм җаваплы эшне тиешенчә башкарып чыга алуларына шөкер итеп.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

М12 – саннарда

- Юлның гомуми озынлыгы – **810** чакрым.
- Төзелеш барышында барлыгы **323** ясалма корылма салганнар.
- Трасса илнең **5** төбәге – Мәскәү, Владимир, Түбән Новгород өлкәләре, Татарстан һәм Чувашия республикалары аша уза.
- **85** меңгә кадәр яңа эш урыны булдырылган.
- Юл төзелешенә инвестицияләрнең гомуми финанс нәтиҗәлелеге **1,8** триллион сум күләмендә бәяләнә.

Вакытыннан алда

М12 «Көнчыгыш» югары тизлекле трассасының Татарстанга туры килүче ике этабының берсен ачу тантанасында Россия Премьер-министры Михаил Мишустин видеоэлемтә аша төзүчеләргә рәхмәт әйтте.

– Барыгызны да әлеге мөһим вакыйга белән котлыйм. Ил эчен юллар белән тоташтыру яхшырганнан-яхшыра. Моны халык та сизә, алар үзләре бу хакта сөйлиләр. Безнең планда Санкт-Петербургтан Владивостокка кадәр барып җиту тора. Моңа системалы рәвештә барабыз, – диде Михаил Мишустин.

Ул билгеләп үткәнчә, Россия Президенты Владимир Путинның барлык боерыклары үтәлә, алай гына да түгел, алар вакытыннан алда тормышка ашырыла. «Сезнең үз эшегезне 8 айга иртәрәк башкаруыгызны беләм», – дип мөрәҗәгать итте ул юл салучыларга.

Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин әйтүенчә, республика илнең алга киткән сәнәгать үзәге булып санала.

– Безнең ирешкән уңышларыбыз заманча транспорт инфраструктурасына да бәйле. Географик яктан уңайлы урнашу бәрабәренә Татарстанда елдан-ел транзит һәм эчке йөк ташу күрсәткече арта. М12 – соңгы дистә елда республикада юл төзелеше өлкәсендә иң зур проект, – диде ул.

Алексей Песошин яңа юлның республиканың визит карточкасына әйләнәчәген һәм ел азагында М12 трассасын тулысынча кулланышка тапшыруны зур түземсезлек белән көтүләрен әйтте.



Зөлфия Хәлиуллина фотолары

ӘЛДЕРМЕШКӘ БАРДЫК ӘЛЕ

Җырларда җырланган, сәхнәләргә күтәрелгән Әлдермеш нинди ул? Авыл халкы башкалардан кайсы сыйфатлары белән аерылып тора, нинди уңышлары бар? Әлеге сорауларга җавап эзләп, без юлга кузгалдык.

Үзе матур, халкы тырыш

Бүген Әлдермештә 221 хуҗалыкта 540 кеше яши. 11 еллык мәктәбе, балалар бакчасы, ФАП, кибете, чишмәләре бар. Халкы терлек тота, кош-корт үстерә. Фермерлары да, эшмәкәрләре дә, авылга ярдәм итеп торучы булдыклы кешеләре дә бар. Якын булгач, Казанга һәм Биектауга йөреп эшләүчеләр дә күп.

Әлдермеш халкы үзләре турында: «Бездә халык бик таләпчән, тырыш, чисталык-пөхтәлек яратучы, усаллыгы да бар», – диде. Чыннан да, авылда тырыш һәм оста куллы кешеләр яши булып чыкты. Яшьләр дә, бәхет эзләп, читкә чәчелмәгән. Биредә балалар туып тора, яңа йортлар салына. Башка авылларда сабыйлар җитмәү сәбәпле, балалар бакчалары, мәктәпләр ябылса, монда, киресенчә, бакчага чират торалар. Бүген анда 51 бала йөри. Капиталь ремонт ясап, урыннар санын тагын да арттырмакчылар.

Яшьләр авылы

Энҗе һәм Илназ Сабировлар – авылда калган шундый яшь гаиләләрнең берсе. Гаилә башлыгының үз эше бар. Энҗе – укытучы. Күптән түгел генә зур купшы йорт салып кергәннәр. Ике кызлары үсеп килә. Төп эшеннән һәм йорттагы мәшәкатьләрдән бушаган арада Энҗе алтын җеп белән шәмаилләр чигә.

– Бу шөгылемне студент елларында башлаган идем. Элек заказга күп эшләдем, хәзер буш вакытым күп түгел, чигүгә ара-тирә генә утырам. Күптән түгел зур шәмаилне 10 мең сумга сатып җибәрдем. 3–4 ай чиктем, – диде Энҗе.

Авылның тоткасы булган туганнантуган егетләр Булат Хәмдиев һәм Марат Бәхтияров, «Хәмдиев» фермер хуҗалыгы оештырып, игенчелек белән шөгыльләнә башлый. Бүген аларның 2300 гектар чамасы җирләре бар. Эшмәкәрләр Биектау һәм күрше-тирә авыллардагы терлекләрне һәм кошкортларны азык белән тәэмин итә.

– Минем нәсел тамырларым – Әлдермештә. Шуңа күрә ул миңа бик якын һәм кадерле, – ди Марат Бәхтияров. – Ул – Казанга иң якын булган татар авылы. Әлдермеш төзек, матур, иң мөһиме: соңгы елларда кеше саны кимеми, яшьләр кала, балалар туып тора. Моның төп сәбәбе, әлбәттә, аның башкалага якын урнашуы һәм халкының тырыш, эшчән булуында. Авылда да яшисе, шул ук вакытта Казаннан еракка да китәсе килмәгәннәр өчен менә дигән җир. Тормыш итәр өчен барлык мөмкинлекләр дә бар. Бездә Сабан туйлары да авыл халкы һәм эшмәкәрләр ярдәме белән бик матур һәм күңелле уза.

Аш-су остасы

Әлдермеш хатын-кызлары элек-электән аш-суга оста, уңган, чиста-пөхтә булулары белән дә аерылып торган. Хәзер дә авылда камыр ашлары әзерләп сатучылар күп. Шундый аш-су остасы Гөлнара Галимҗанова белән таныштык. Без аны, яратып, «Әлдермеш кояшы» дидек. Чөнки нәкъ кояш кебек нур балкытып каршы алды безне Гөлнара ханым.

– Егерме ике ел элек әлеге йортка килен булып төштем. Авылга Казаннан беренче тапкыр кайтуым әле дә истә. Ул вакытта булачак иптәшем мине Сабан туена алып кайтты. Шулкадәр нык яраттым Әлдермешне! Туганнарына да, авылның халкына да, табигатенә дә, мондагы тәртип, чисталык-пөхтәлеккә дә гашыйк булдым. Хатын-кызлары төрледән-төрле пироглар, тортлар, урама, чәкчәк пешерәләр. Токмачларга кадәр кисеп саталар. Каенанам да аш-суга бик оста иде, – дип искә алды Гөлнара ханым.

Каенанасы Рәсимә апаның иң яратып һәм оста итеп әзерли торган ризыкларының берсе урама булган.

– Элек дәү әни, әниләр исән чагында, Коръән ашлары, мәҗлесләр уздырырга бер атна кала барлык туганнар җыела иде. Ә каенатамнар – сигез бертуган! Кем катык оета, кем эремчек төшерә, кем каймак чыгара, кем камырга тотына. Кыскасы, йортыбыз умарта күчен хәтерләтә иде. Туганыбыз Кафия апа урама камырын җәйсә, әни аны пешереп тора. Бервакыт шулай урама пешергән вакытта телефон шалтырады да, әни сөйләшергә китте, ә миңа аны алыштырырга туры килде. Беренче чирканчыкны шунда алдым. Башка вакытта да әни җәйгәнне миңа пешерергә калды, – дип искә алды хуҗабикә урама пешерә башлау тарихын.

Кызганыч, өч ел элек бер-бер артлы каенанасы белән каенатасы мәрхүм була. Киленнәре аларны бик яратып искә алды.

– Әниебез ашларга бик зурлап, үзе пешергән күчтәнәчләр белән барырга ярата иде. Мин дә нәкъ шулай ук. Авылыбызның Зөмәрә абыстае да – бик оста куллы ханым. Никахка барганда ул үзенең данлыклы кабартмаларын пешерә. Аларның уңу-уңмавына карап, яшьләрнең киләчәген, хуҗалыкларның холкын чамалап була, дип әйтә. Мин дә шуны ук урама турында әйтә алам. Ачык, киң күңелле кешеләргә булганда, эшем дә бик уңайлы, җайлы бара. Кайбер кешегә пешергәндә бераз мәшәкатьләнергә туры килә, – ди ул.

Гөлнара ханым баштагы вакытларда күчтәнәчкә алып барса, хәзер башкалар да бәйрәм табынына урама пешереп бирүен сорый икән. Авылдашларына булдыра алганча ярдәм итәргә тырыша ул.

Тимернең холкы яман

Авылның тагын бер остасы – капка ясаучы Әдһәм Хәбибуллин. Ул тимердән капкалар, коймалар, чардуганнар, мунча мичләре, баскычлар ясый.

– Сатып алучыларның да зәвыклары елдан-ел үзгәрә, матуррак, бизәкләре күбрәк булган, катлаулырак капка сорыйлар. Шул ук вакытта гадирәкләрен дә алучылар күп. Соңгы вакытта капкаларга заказлар алмый башладым, чөнки аларны эшләр өчен күп көч кирәк. Шуңа күрә соңгы елларда башлыча чардуганнар ясауга күчтем. Тимернең дә үз холкы бар. Ул дымлы җирне яратмый. Артык каты тимер белән дә эшләү бик авыр, күп көч таләп итә. Булдыра алганда, мөрәҗәгать итүчеләрне кире борып җибәрмәскә тырышам, – диде оста.

Иң кыйммәтле эше дип, җиде ел элек 100 мең сумга эшләгән капканы әйтте. Хәзер исә бер кешелек чардуганнарны – 24–26 меңгә, ике кешелекләрне 35–40 мең сумга ясый.

Клуб кирәк

Зур авылы да, кечкенәсе дә үз борчумәшәкатьләре белән яши. Әлдермештә дә бар алар. Әйтик, халык белән аралашкан вакытта, авылның йөзе, асылы үзгәрә, дип борчылуларын әйттеләр.

– Авылыбыздагы буш йортларга башка милләт кешеләре кайтып төпләнде. Элек без тагын да бердәмрәк, ачыграк идек. Урамда күрешеп, һәркем хәл-әхвәл белешә иде. Хәзер исәнләшмичә китүчеләр дә бар. Менә шунысы бераз күңелне кыра, – ди алар.

Шундый зур, матур һәм төзек авылның клубы булмау да гаҗәпләндерде. Моңа кадәр иске бинада эшләп торганнар, быелдан анысында да җылылык бирүне туктатканнар. Мәдәният йорты хезмәткәре Эльмира Фәрхетдинова әйтүенчә, соңгы вакытта бәйрәмнәр мәктәп һәм балалар бакчасында узган. Җәйге матур көннәрдә исә алар капка төпләрендә, ял паркында җыелган.

– Клуб мәсьәләсендә боз кузгалган да иде, тик ни сәбәпледер эшләр туктады. Шулай да без яхшыга өметләнәбез, киләсе елларга булса да авылыбызда матур клуб сафка басар, дип ышанабыз, – диде ул.

Әлеге мәсьәлә буенча Биектау районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ринат Сабирҗановка мөрәҗәгать иттек.

– Клубның нигезе салынган, үзе дә эшләнеп бетәчәк, – диде ул. – Район башлыгы Равил Хисаметдинов аны 2024 елда программага кертү өчен тырыша. Клуб хезмәткәрләре эшсез калмады, әлегә эшчәнлекләрен мәктәп базасында дәвам итә. Әлдермеш авыл җирлегенә кергән Сая авылында да 45 урынга исәпләнгән клуб булачак.

Зөһрә САДЫЙКОВА

24 ноябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Ләйсән САФИНА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Юл акчасы кайда?

Ирем дә, мин дә – хезмәт ветераннары. Октябрь аенда юл акчасын дөрес түләмәделәр. Имеш, алдагы айда утка, газга субсидияне артык түләгән булганнар да октябрьдә шуны тотып калганнар. Без акча күбрәк килгәнне белмәдек. Көннәр суыткан саен коммуналь хезмәтләр өчен субсидия күләме болай да арта бит. Бер төр түләүне икенчесеннән тотып кала алалармы?

Исемем редакция өчен генә.
Аксубай районы

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татьяна Кандалина, Матди ярдәм күрсәтү буенча республика үзәгенең Аксубай муниципаль районындагы 4 нче номерлы бүлеге җитәкчесе:
– Субсидия алучыга сентябрь аенда газ өчен түләү күчкәннән соң, газ оешмасы хезмәткәрләре безгә яңадан ясалган исәп-хисап кәгазьләрен җибәрде. Аның нигезендә субсидия күбрәк түләнгән булып чыкты. Пенсионерны әнә шул бурычны безгә кире кайтару мәшәкатеннән азат итү өчен, без әлеге сумманы юл акчасыннан тотып калдык. Иренә бәйле дә шул ук хәл. Шуңа күрә октябрь аенда субсидия азрак килгән. Хәзер күрсәткечләрне дөресләдек. Ноябрь аеннан акча элеккечә киләчәк.

Автобус буламы?

Буадан Тәтешкә бара торган автобус йөрүдән туктады. Безгә аңлатуларынча, автобус йөртүче таба алмыйлар. Буада – ветеринария техникумы, медицина көллияте, Тәтештә авыл хуҗалыгы техникумы бар. Ягъни ике район арасында гел студентлар йөреп тора. Шуңа күрә автобусны туктатулары бик начар булды. Җомга, шимбә һәм якшәмбе көннәрендә генә булса да җибәрә алмаслармы икән аны?

Сахаутдин РӘХИМОВ.
Буа районы Янтуган авылы

Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының матбугат хезмәтеннән:
– Министрлык тарафыннан 122 нче номерлы «Тәтеш – Буа – Тәтеш» һәм 126 нчы номерлы «Буа – Тәтеш – Буа» районара даими маршрутлар оештырылган. Моңа кадәр бу маршрутларда шәхси эшмәкәр Әсгать Рафиков хезмәт күрсәтте. Хәзерге вакытта эшкуарның әлеге эшкә рөхсәт бирү таныклыгы гамәлдән чыккан. Шуңа күрә 122 нче номерлы «Тәтеш – Буа – Тәтеш» һәм 126 нчы номерлы «Буа – Тәтеш – Буа» районара даими маршрутларына яңа пассажир йөртүчене билгеләү өчен, конкурс процедураларын оештыруга бәйле эш алып барыла.

Кайчан сырхауханә төзерләр икән?

Казанның «Салават Күпере» торак комплексында халыкка тиешле хезмәт күрсәтүче сырхауханә юк. Табиблар көнгә 2–3 сәгатькә генә килеп китә, тик белгечләр юк. Безне Казанның Назарбаев урамындагы дәвалау учреждениесенә җибәрәләр. Мин – өлкән кеше, анда барып йөрергә мөмкинлегем юк. «Салават Күпере» торак комплексында бөтен белгечләре булган сырхауханә кайчан ачылыр икән?

Екатерина ПОРФИРЬЕВА.
Казан

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының матбугат хезмәтеннән:
– Халыктан килеп ирешкән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә «Салават Күпере» торак массивында яңа күппрофильле сырхауханә төзелеше башланды. Киләчәктә биредә яшәүчеләр яңа бинада амбулатор-поликлиника ярдәме ала алачак, шул исәптән анда диагностика үтү һәм төрле белгечләр консультацияләре дә каралган. Сырхауханә проектында хатын-кызлар консультациясе, травмпункт, ашыгыч ярдәм станциясе бар. Медицина учреждениесе бер сменага 750 кешене кабул итәчәк дип фаразлана. Ул 50 мең өлкән кешегә һәм 15 мең балага исәпләнгән. Объектны 2024 ел ахырында кулланышка тапшырырга ниятлиләр.

Кәгазь полис кирәкме?

Машина йөртүчеләргә электрон иминият полисын кәгазьдә бастыру мәҗбүриме?

РИФАТ К. Биектау

Рөстәм Гарипов, Татарстан Дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы:
– Закон буенча электрон иминият полисын кәгазьгә бастыру мәҗбүри һәм аны үзең белән йөртергә кирәк. Закон буенча машина йөртү таныклыгы да булырга тиеш. Әмма хәзер кесә телефоннарында электрон машина йөртү таныклыгы дигән махсус кушымта бар. Таныклык үзе белән булмаса, машина йөртүче инспекторга электрон документны да күрсәтә ала.

Теш куялармы?

Картлык шатлык түгел. Эшләргә – көч, ашарга теш калмады. Хезмәт ветераннарына бушлай теш протезлары куялар дип ишеткән идем. Бу дөресме? Моның өчен кая мөрәҗәгать итәргә кирәк?

Мансур ЗАКИРОВ.
Кама Тамагы

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика стоматология сырхауханәсе хәбәреннән:
– Татарстанда ташламага ия булучыларга Республика стоматология сырхауханәсенең ортопедия бүлегендә бушлай теш протезлары куялар. Әлеге төр хезмәтне өч елга бер тапкыр алырга мөмкин. Теш протезларына бер ел гарантия бирелә. Аны куйдыру вакытының ике айга кадәр сузылуы бар. Чират юк диярлек. Татарстанда аерым категория гражданнарга теш протезы кую хезмәте ТР Министрлар Кабинеты карары белән расланган. Әлеге документ нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирү яшенә җиткән хезмәт ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәте өчен СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнүчеләр, реабилитацияләнүчеләр, сәяси репрессияләрдән зыян күрүчеләр, ТР дәүләт бүләкләренә лаек булган пенсия яшендәге кешеләр бушлай теш протезы куйдыру хокукына ия. Тулырак мәгълүматны 8 (843) 236-46-21 (регистратура) телефон номеры аша алырга мөмкин.

Кредит кайтамы?

27 ел бергә яшәгән ирем белән аерылыштык. Буа районында яшәгән йорттан Казанга туганнарыма чыгып китәргә мәҗбүр булдым. Мин кияүгә чыкканда, иремнең иске генә йорты бар иде, милек аның исемендә. Бөтен көчебезне, эшләгән һәр тиенне шул йортка кертеп, капиталь ремонт ясадык. Дивар, тәрәзәләрне яңарттык, йорт җиһазлары сатып алдык. Мунча, веранда эшләттек. Былтыр ремонт эшләренә дип минем исемгә кредит алган идек, хәзер ул йортта яшәмәсәм дә, ай саен 13 мең сум кредит түлим. Без әле рәсми рәвештә аерылышмаган. Ирем дә, туганнары да, синең бу йортта бер нәрсәң дә юк, диләр. Кредит акчасын булса да кайтарып булмасмы икән? Аны мин үземә тотмаганны ничек расларга?

Гәүһәрия ХӘЙРУЛЛИНА

Булат Закиров, «ВТ» юристы:
– РФ Гаилә кодексының 38 маддәсе нигезендә, ир белән хатынның уртак милкен бүлгәндә, аларның һәрберсенә нинди милек тапшырылырга тиешлеге билгеләнә. Әгәр ир белән хатынның берсенә тиешледән артык бәядәге мөлкәт бирелсә, икенчесенә акчалата яки башка төр компенсация булырга мөмкин. Гаилә кодексы нигезендә, ир белән хатынның уртак мөлкәтен бүлгәндә, аларның гомуми бурычлары бирелгән өлешләргә пропорциональ рәвештә бүленә. Сезгә аерылышу һәм уртак милекне бүлү турында гариза белән судка мөрәҗәгать итәргә киңәш итәбез. Әйе, сез өйгә дәгъва итә алмыйсыз, ләкин ремонт өчен компенсация сорый аласыз. Әлеге эшкә үз акчагызны тотканны исбатлау өчен, судка бар булган дәлилләрегезне тапшырырга кирәк: ремонтны гамәлгә ашыру буенча килешүләр, чеклар, квитанцияләр, банктан белешмәләр, хат алышулар һ.б. Кредит шәхси максатлар өчен түгел, ә гаилә ихтыяҗлары өчен рәсмиләштерелгәнгә күрә, ул суд карары нигезендә бүленергә тиеш.

Эльвира ВӘЛИЕВА әзерләде

Рәхмәт ишетү рәхәт

«Ватаным Татарстан» газетасы аша күз табибына рәхмәтемне белдерәсем килә. 2003 елның 18 маенда районнан Казанга күз табибына күренергә дип килдем. Мине бер хатын-кыз кабул итте. Авыруның җитди булуын, операция ясарга кирәклеген әйтте. Әмма әлегә урын юк, көзгә килерсез, дип чыгарып җибәрде. Коридордан барганда, районга килеп, күземне тикшергән табиб очрады. «Абзый, нишләп йөрисез?» – ди бу. Сөйләп бирдем. Шуннан соң табиб мине бүлек мөдиренә алып кереп китте дә, олы кешене йөртмик инде дип, икенче көнне үзе миңа операция ясады. Мин аңа беркем дә түгел. Кеше аша белдем: Буа районының Бик-Үти авылы егете икән ул. Еллар узды. Мин әле дә күзлек кимим, рәхәтләнеп укыйм, язам. Гомерем буе Рамил Равил улы Гыйммранова рәхмәт укыдым. Табибларның төрлесе бар. Әмма мондые берәү генә! Мең рәхмәт сезгә, Рамил туган!

Хәйдәр ИСРАФИЛОВ.
Мамадыш районы Түбән Яке авылы

20 ноябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16 +
11.30 «Халкым минем…» 12+
12.00, 22.40 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00, 01.05 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 12+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «ТРЮКАЧ» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Путь» 16+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12 +
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

006.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05, 03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 02.40, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25, 00.40 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Туган авылым» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
02.40 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 16.55 Новости
07.05, 19.00, 21.45, 00.45 Все на Матч!
10.05 «Лица страны» 12+
10.25 «Звёзды без правил» 12+
11.25, 22.35 Футбол. Чемпионат Европы-2024. Отборочный турнир
12.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!»
14.20, 05.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов [6+]
14.55 Смешанные единоборства. UFC. Брендан Аллен против Пола Крейга 16+
16.00 «Громко»
17.00 Плавание. Чемпионат России
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. СКА (Санкт-Петербург) – ЦСКА
01.40 Биатлон. Кубок Международной Лиги. Масс-старт. Гонка преследования. Мужчины 0+
03.25 Новости 0+
03.30 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Динамо» (Москва) – «Белогорье» (Белгород) 6+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
22.15 «ЛИХАЧ» 16+
00.50 «ПОТЕРЯННЫЕ» 16+
03.30 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35, 05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.35 «Тест на отцовство» 16+
10.45, 23.10 «Понять. Простить» 16+
11.50, 00.20 «Порча» 16+
13.00, 01.20 «Знахарка» 16+
13.35, 01.45 «Верну любимого» 16+
14.10, 02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45, 02.35 «В ОТРАЖЕНИИ ТЕБЯ» 16+
19.00 «КОМНАТА РОЗ» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «СНАЙПЕР. ОРУЖИЕ ВОЗМЕЗДИЯ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «КЛЮЧИ ОТ НЕБА» 12+
12.45, 03.35 «СПЕЦОТРЯД «ШТОРМ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Неизвестные сражения Великой Отечественной» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «Шедевры военных музеев» 12+
00.15 «ВЕРЕВКА ИЗ ПЕСКА» 16+
02.55 «Из всех орудий» 16+

21 ноябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.15, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 18.45, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 16.30 «АЛМАШ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15, 00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
17.15 «Казаннан – Казанга» 16+
17.45, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
19.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Динамо» (М) – «Ак барс» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «ТРЮКАЧ» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30. 18.20, 23.10,Ю 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05 «Ком сәгате» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.15, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
21.25 «Ком сәгате» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00, 18.30 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «МОСГАЗ. ПОСЛЕДНЕЕ ДЕЛО ЧЕРКАСОВА» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Сядь нормально» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Драгоценные истории» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ЕКАТЕРИНА. ФАВОРИТЫ» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.05 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
02.40 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 16.55, 18.50 Новости
07.05, 16.00, 21.45, 00.45 Все на Матч!
10.05, 12.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Звёзды без правил» 12+
11.25, 22.35 Футбол. Чемпионат Европы-2024. Отборочный турнир
13.00 «Есть тема!»
14.20 «География спорта» 12+
14.55 Профессиональный бокс. Дмитрий Бивол против Джексона Джуниора. Денис Лебедев против Латифа Кайоде 16+
17.00 Плавание. Чемпионат России
19.00 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» (Москва) – «Ак барс» (Казань)
01.40 Биатлон. Кубок Международной Лиги. Масс-старт. Гонка преследования. Женщины 0+
03.20 Новости 0+
03.25 Футбол. Чемпионат мира-2026. Отборочный турнир

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
22.15 «ЛИХАЧ» 16+
00.50 «ПОТЕРЯННЫЕ» 16+
03.30 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

07.35 «Давай разведёмся!» 16+
08.35 «Тест на отцовство» 16+
10.40, 23.20 «Понять. Простить» 16+
11.45, 00.30 «Порча» 16+
12.55, 01.25 «Знахарка» 16+
13.30, 01.50 «Верну любимого» 16+
14.05, 02.20 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «Твой Dомашний доктор» 16+
14.55, 02.45 «МЕЛОДИЯ ЛЮБВИ» 16+
19.00 «КОМНАТА РОЗ» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «МОРСКОЙ ОХОТНИК» 12+
12.45, 03.35 «СПЕЦОТРЯД «ШТОРМ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Неизвестные сражения Великой Отечественной» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «Шедевры военных музеев» 12+
00.15 «ВЕРЕВКА ИЗ ПЕСКА» 16+
02.55 «Из всех орудий» 16+

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНҮ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ
20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

ЯШЬКӘ КАРАМЫЙ

Россиядә ел саен 500 меңгә якын кеше инсульт кичерә. Шуларның 30 проценты – әле 40 яшькә дә җитмәгән, дип чаң суга белгечләр. Әлеге мәкерле авыру ни сәбәпле яшәрә? Аны алдан кисәтеп буламы?

Табиб-невролог, реабилитолог, медицина фәннәре кандидаты Диләрә ШАҺИЕВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Соңгы елларда инсульт ни сәбәпле яшәрә?

– Кызганыч, инсульт, дөрестән дә, елдан-ел яшәрә бара. Билгеле булганча, аның ишемик һәм геморрагик төрләре була. Геморрагик инсульт нәкъ менә яшьләр арасында күбрәк очрый. Бу иң беренче чиратта яшәү рәвешебезгә бәйле. Дөрес тукланмау, аз хәрәкәтләнү, тәмәке тарту кебек начар гадәтләр белән мавыгу, даими рәвештә стресста яшәү инсульт килеп чыгу ихтималын бермә-бер арттыра. Әлеге диагноз спортчылар арасында да еш очрый. Бу, иң беренче чиратта, аларның физик күнегүләр белән артык мавыгып, организмны ял иттерергә онытулары аркасында килеп чыга. Шикәр чире, атеросклероз авыруларыннан интегүчеләр, сәламәт яшәү рәвеше алып бармаучылар, кандагы холестерин күләме югары булган кешеләр дә – инсульт куркынычы янаучылар төркемендә. Эш урынында, шулай ук гаджетлар каршында утырганда баш, муен өлешләренең дөрес халәттә булмавы да инсульт куркынычын бермә-бер арттыра. Ник дигәндә, баш озак вакыт дәвамында иелеп торса, кан тамырларына зыян килә. Инсульт нәселдән дә күчә ала.

:: Ишемик инсульт геморрагик инсульттан нәрсәсе белән аерыла?

– Ишемик инсульт күбрәк өлкән яшьтәгеләр арасында очрый. Ул, гадәттә, иртәнге якта аяктан ега. Кан басымы уйнаган, бигрәк тә кан басымы югары булган кешеләрне үз итә ул. Моңа еш кына аларның тиешле даруларны вакытында эчмәве дә сәбәп булып тора. Юкса, гипертония вакытында аларны гел эчеп торырга кирәк. Геморрагик инсульт исә, киресенчә, көндез актив рәвештә ниндидер эш башкарганда тотып ала. Шуңа күрә ул күбрәк яшьләр арасында очрый. Геморрагик инсульт, гадәттә, баш миендә аневризма күзәтелгәндә, ягъни кан тамыры бүлтәеп чыгып, кан йөреше бозылу аркасында килеп чыга.

:: Кайсы чирләр инсультка китерә ала?

– Атеросклероз, шикәр чире, югары кан басымыннан интеккән кешеләр арасында инсульт күбрәк очрый. Соңгыларына үз сәламәтлегенә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Ник дигәндә, кан басымы югары булган кеше ахыр чиктә бу халәтенә ияләшә, аны даими рәвештә үлчәми, даруларын вакытында эчми башлый. Безгә килгән бер авыруның кан басымы 225кә меңгән иде. Ул исә үзен бик яхшы хис итүен әйтте. Артык авырлыктан, симерүдән интеккән кешеләргә дә инсульт куркынычы яный. Нәселендә инсульт, инфаркт кичерүчеләр булган кешеләргә дә сак булырга кирәк.

:: Инсультны нинди билгеләр буенча чамаларга?

– Гадәттә, кеше ишемик инсультның билгеләрен генә аерымачык сизә ала. Кеше елмайса, авызы бер якка чалшайган була. Сөйләшсә, нәрсә сөйләгәне аңлашылмый. Кулларын алга сузуын сорасаң, бер кулы төшеп китәчәк. Геморрагик инсульт вакытында инде кеше урын өстенә кала, бөтенләй хәрәкәтләнә алмый.

:: Табиб килеп җиткәнче, кешегә ничек ярдәм итәргә?

ИНСУЛЬТНЫ КИСӘТҮ ӨЧЕН НИЧЕК ТУКЛАНЫРГА?

➤Майлы ризыкларны чамасын белеп кенә кулланыгыз. Ашаган ризык составында трансмайлар, пальма мае булмаска тиеш. Соңгы арада азык-төлек капларында «үсемлек майлары» дигән сүз еш очрый. Еш кына анда пальма мае да керә. Шуңа күрә составында нинди май кулланылуы конкрет күрсәтелгән ризыкларны гына алыгыз.

➤Чипсы, кириешка, фастфуд кебек зарарлы ризыклардан да баш тарту хәерле.

➤Шикәр дә – төп дошманнарның берсе. Ул артык авырлык җыюга, шикәр чиренә китерә. Ул исә, үз чиратында, инсульт килеп чыгу куркынычын бермә-бер арттыра.

➤Каһвә эчәргә яратучыларга да игътибарлы булырга кирәк. Геморрагик инсульт алар арасында да еш очрый. Шуңа күрә каһвәдән баш тартып, яшел чәйгә өстенлек бирсәгез, яхшырак булыр.

➤Инсульттан саклану өчен, көненә ярты килограмм чамасы яшелчә, авокадо, чикләвек ашарга кирәк. Үсемлек мае урынына зәйтүн маен куллану хәерлерәк.

➤Диңгез балыгы да файдалы. Анда омега-3 күп.

➤Кибеттә сатылган камыр ризыклары, тәм-томнарда күпчелек пальма мае кулланыла. Шуңа күрә әлеге төр ризыктан авыз итәсегез килсә, аны үзегез пешерегез.

– Аны урынга яткырып, башын азрак күтәрергә кирәк. Башын янга борып куярга да онытмагыз. Моны, коса калса, тончыкмасын өчен шулай эшләргә кирәк. Аннары аның кан басымын үлчәргә. Инсультлы кешегә башкача берничек тә ярдәм итеп булмый. Аңа үз белдегең белән ниндидер дару эчертү дә тыела.

:: Инсультны алдан кисәтү өчен ни эшләргә?

– Моның өчен иң беренче чиратта дөрес тукланырга кирәк. Көнәнә өч тапкыр бер үк вакытта тукланырга тырышыгыз. Ач карынга кибеткә керүдән дә саклагыз. Бу организмга теләсә нинди ризык эләкмәсен өчен кирәк. Бик тә баллы ризык ашыйсыгыз килсә, башта берәр файдалы ризык ашагыз. Ахырдан гына десерт урынына берәр печенье яки җиләк-җимеш кабып куярга була. Даими рәвештә хәрәкәттә булыгыз. Физик күнегүләр дә инсультны кисәтергә ярдәм итә. Көн дәвамында чиста су эчәргә дә онытмагыз. Яшел чәй, составында омега-3 күп булган ризыкларга өстенлек бирегез. Даими рәвештә табибка күренеп, сәламәтлегегезне тикшертеп торырга да онытмагыз.

Тәрәзә төбем яран гөл

Тәрәзә төпләрендә йортка нур өстәп торган яран гөл матур булудан бигрәк, сәламәтлек өчен файдалы, ди белгечләр.

Салкын тиюдән. 1 литр суга 25 г яран гөл яфракларын салып, 10 минут кайнатасың. Аннары тамакны шушы су белән чайкатырга кирәк.

Томау төшүдән. Яран гөл яфраклары согын борынга тамызып, томау төшүдән котылырга була.

Кан басымыннан. Яран гөл яфрагын беләзек турысына куеп, кан басымын җайларга мөмкин. Аның өчен яфракны кулда угалап, бераз суын чыгарырга кирәк.

Отит вакытында. Колак авыртуын басар өчен дә яран гөл яфрагы ярдәмгә килә. Йоклар алдыннан яфракны бөтереп, колакка куеп торырга була.

Теш сызлаганда. Яран гөл яфракларын чәйнәргә кирәк. Ул, стафилококкны бетерә торган бактерицид матдәләр бүлеп чыгарып, төрле ялкынсынулардан саклый.

Тире өчен. Яран гөл составындагы эфир майлары тирегә уңай тәэсир итә, төрле тимгелләрне бетерә, экзема кебек авыруларга каршы дәва булып тора. Шулай ук ярадагы үлекләрне суыра, пешкән, янган тирене тизрәк төзәтә.

Остеохондроз, радикулиттан. Яран гөл яфрагыннан компресс ясап, остеохондроз, радикулитны да дәвалап була.

Чәчләргә шифа. Чәчне яран гөл төнәтмәсе кулланып юсаң, чәч коелмый башлый.

Арыганлыктан. Моның өчен яран гөл яфрагын кулда уарга кирәк. Ул арыганлыкны бетерә, кәефне күтәрә, стресс, депрессиядән коткара.

Йокысызлыктан. 10 яфракны 1 стакан кайнар суга салып, 1 сәгать салкын урында тотарга кирәк. Йоклар алдыннан шушы төнәтмәне стаканның өчтән бере күләмендә эчәргә мөмкин.

Киңәш

Биткә файдалы

Көн суыту белән, бит тиресе корый. Коры тире тиз картая, җыерчыклана. Шуңа күрә аны даими дымландырып торырга кирәк. Бу очракта махсус спрей ярдәм итә.

Унар тамчы лимон, пихта, лаванданың эфир маен, 1 аш кашыгы глицерин һәм 1 аш кашыгы медицина спиртын бергә кушыгыз. Аны 1 стакан кайнап суынган су белән сыеклап, сиптергечле кечкенә шешәгә бушатыгыз.

Көн дәвамында шушы катнашманы битегезгә сиптереп, тирене дымландырып торыгыз.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Бакчачыга

Виноград кышка әзерләнә

Виноградның кышны исән чыгуы аның сорты, яше, каплануы һәм елның нинди килүенә дә бәйле. Хәзер кышка чыдам виноград сортлары да күп. Тик утыртканнан соң ике елга кадәр виноградларны кышка каплап калдыру хәерле. Аларны кичен салкыннар даимигә әйләнгәннән соң, температура 0 һәм берничә градус җылы булган вакытта капларга кирәк. Аны кышка әзерләү өчен, 15 минут чамасы вакыт таләп ителә. Виноград рәтенә параллель рәвештә тирән булмаган траншея казырга. Аңа калын итми генә чыршы ботаклары җәяргә. Аның өстенә виноград сабагын җайлап кына салып, өстен дә чыршы белән капларга. Өстенә полиэтилен җәяргә була.

Каплау өчен шулай ук тыгызлыгы 60 г/м^2 булган спанбонд, агач чүбе, коры кипкән яфраклар кулланырга була.

Әлбәттә, бер капладың да оныттың түгел. Һава торышындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә виноградның кыш чыгуын күзәтеп торырга кирәк. Тычканнар зыян салмасын өчен, агу куеп калдыру да зыянга булмас.



БОРАЙ ОЗАК ПЕШЕРГӘННЕ ЯРАТА

Кукмара элеваторында пешекче булып эшләүче Дилбәр Гаязова 38 ел буе аш-су өлкәсендә хезмәт куя. Әлеге ашханәдә эшләвенә сигез ел булган. Ул борай бәлешен Россиягә таныткан кеше икән.

– Саба кызы мин. Кукмара егетенә кияүгә чыктым. Шуннан бирле гел ризык әзерләүдә инде, – ди Дилбәр Гаязова. – Җитәкчелеккә рәхмәт. Алар ашханәдәге бәяләрне арттырмый. Максатлары – акча эшләү түгел, халыкны тәмле итеп ашату. Көненә 800ләп кеше керә безгә. Ашханәдә барлыгы биш кеше эшлибез. Кызларның барысы да бик уңган. Иртәнге 8дә эшли башлыйбыз. 10га кадәр чәй эчәргә керүчеләр бик күп. Аларга өчпочмак белән коймакны җиткереп булмый. Мич коймагын дүшәмбе көнне – өч йөзне, җомга – биш йөз, калган көннәрне дүрт йөзне пешерәбез.

ПЕШЕРҮ СЕРЛӘРЕ

✓Ботка пешерү өчен борайның ярдырылганы кирәк. Аны суга салып, сүрән утта 2 сәгать чамасы пешерәсе. Пешеп чыккач кына тоз һәм шикәр комы салып, атланмай кушып, ботканы өлгертәсең.

✓Борай бәлеше өчен ярманың ярдырылмаганы кирәк. Аны бер көн алдан пешереп куйсаң, яхшы. Бәлеш ярмасын да сүрән утта бик озак пешерергә кирәк.

✓Бәлешкә диган борайны, пешкәч сүндереп, суында тотарга киңәш итәм. Ярма таралып тора торган булачак. Аннары инде шул ярмага каз һәм сыер итен турап саласы гына кала.

✓Эчлеккә суганны саргылт төскә кергәнче кыздырасы, түменчә тоз өстисе. Борай бәлеше камыры ит бәлешенеке кебек үк ясала.

Дилбәр ханым аш һәм икенче ризыкларны әзерли икән. Борай ярмасын аның кебек оста пешерүче юк, диделәр. Без дә борай пешерү серләрен белештек.

– 2022 елда район Сабан туенда авырлыгы – 199 килограмм, диаметры 150 сантиметр булган итле борай бәлеше, 2023 елда борай боткасы пешереп, Россиянең Рекордлар китабына кердек. Борай бәлешен элек-электән әби-бабайлар пешергән. Кукмараның йөзек кашы ул! – ди Дилбәр ханым.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Белеп тор!

Тәмле шулпа сере

- Ашка аз-азлап берничә төрле ит салсаң, шулпа тәмлерәк була. Мәсәлән, сыер яки сарык ите янына бераз гына кош ите – каз, үрдәк, тавык ите салып җибәрсәгез, шулпа телеңне йотарлык булачак.
- Тәмле шулпа ашыйм дисәгез, аны ашык-пошык пешермәгез. Кайнап чыгып, күбеген алганнан соң, сүрән утта кимендә сәгать-сәгать ярым кайнатылган шулпа тәмле дә, файдалы да була.
- Ашка ит белән бергә бер баш суган салып кайнатсагыз, шулпа хуш исле булыр. Аннары суган турап саласы да булмый.
- Ит шулпасына тозны әзер булганчы 30 минут алдан, балыкныкына пешерә башлаганда ук, гөмбә шулпасына иң ахырдан гына салырга киңәш ителә.

Тәмле булсын!

КАЗАН ТӘКӘСЕ

Марьям МИННЕГУЛОВА рецепты

Камыр өчен кирәк: ярты стаканнан азрак су, 1 аш кашыгы үсемлек мае, тоз, стакан ярым он.

Эчлек өчен кирәк: эремчек, йомырка, тоз, бераз шикәр комы.

Барысын кушып камыр басабыз. Җәем җәеп, кисеп, эчлек салып бөгәбез дә тозлы, әз генә май салынган кайнаган суда пешереп алабыз, ахырдан майлыйбыз.

ӨЛЕШ ӨЧЕН КАМЫР

Гөлчәчәк ФӘТХУЛОВА рецепты

Камыр өчен кирәк: 180 г 20 процентлы каймак, 2 йомырка, 100 г йомшартылган атланмай, ярты кашык чамасы камыр көпшәкләндергеч (разрыхлитель), ярты кашык тоз, ярты кашык шикәр комы, чама белән он.

Эчлек өчен туралган ит, бәрәңге, тоз-борыч, суган кирәк. Әлеге камыр өчпочмак өчен дә яхшы.

10 тавыкка – 50 йомырка

«ВТ» сайтында, тавыклар йомырка күп салсын өчен, сода бирергә кирәк, дип язган идегез. Аны биреп караганыбыз юк. Тик безнең тавыклар да йомырка салу буенча кимен куймый. 10 тавыктан атнасына 45–50 йомырка җыеп алабыз.

Безнең тавыклар рационында түбәндәгеләр бар: тегермәндә тарттырылган арпа, бодай, солы; пешерелгән бәрәңге, арпа, алма; коры арпа белән бодай; җебетелгән ипи; җәй буе яшел үлән; кабырчык (ракушка), йомырка кабыгы.

Көзен бакчада тишелеп чыккан уҗым һәм горчица йолкып бирәбез. Кышын ризыкларына аз-азлап арзанлы көнбагыш кушабыз. Ел буе 10 тавыкка дөнья йомырка җыеп алабыз, балаларга бирәбез. Менә шулай, милләттәшләрем, өйдә утыручы пенсионер бабай шулай сыйлый безнең тавыкларны.

Рәфилә ФӘТТАХОВА

Укучы киңәше

«ЯШЕЛ ТӘМЛҮШКӘ»

Фейхоаның файдалы икәнен аңлатып тормыйм. Аны сатуга чыгуга туңдырып куярга тырышам. Моны кайнатып ясамагач, «кайнатма» дип әйтмим, «яшел тәмлүшкә» дип йөрим. Чәй эчү өчен әкәмәт шәп инде!

1 кг фейхоага ярты кг шикәр комы алам. Юып чистартылган фейхоаны иттарткычның эре тишеклесеннән чыгарам да шикәр комы салып болгатып, суыткычның катыра торган өлешенә куям. Блендер белән дә вакларга була. Ә мин үзем эрерәк кисәкләре булганны яратам, шуңа иттарткыч аша чыгаруны кулай күрәм.

Ашар алдыннан алып җебетәм. Әлеге тәмлүшкә файдалы булудан тыш, кәефне дә күтәреп җибәрә.

Галия САФИНА. Казан

ҮТӘРДӘЙ БУЛМАСАҢ, ӘЙТМӘ...

Аллаһы Тәгаләгә биргән вәгъдәне бозу динебездә икейөзлелек буларак бәяләнә. Шуңа күрә нәзер әйткәндә бик сак булырга киңәш ителә. Әйтеп, нәзереңне үти алмаган очракта ни эшләргә?

Әмәт бистәсе мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт БИКБАЕВ нәзергә кагылышлы сорауларыбызга ачыклык кертте.

Нәзер ул – кешенең Аллаһы Тәгалә тарафыннан йөкләнмәгән әйберне үзенә бурыч итеп алуыннан гыйбарәт. Ул аны һичшиксез үтәргә тиеш була. Нәзер, гадәттә, Аллаһы Тәгалә рөхсәт иткән әйберләр буенча әйтелә. Ягъни кеше намаз уку, сәдака бирү, ураза тоту, корбан чалу ише гамәлләрне үзенә нәзер итеп алырга мөмкин.

:: Нәзернең нинди төрләре була?

– Нәзер өч төрле була. Беренчесе фәкать нәзер әйтүдән генә гыйбарәт. Мисал өчен, кеше: «Аллаһ ризалыгы өчен дүшәмбе көнне ураза тотам», – дип нәзер әйтә ди. Бу очракта ул изге гамәлне беренди әйбергә бәйләмичә, вәгъдә рәвешендә әйтә. Билгеле бер шарт белән әйтелгән нәзерләр була. Мәсәлән, кеше: «Улым армиядән исән-сау кайтса, сәдака бирер идем», – дип әйтергә мөмкин. Бу очракта, шушы шарт үтәлсә, ул нәзер итеп әйткән әйберне башкарырга тиеш була. Ләкин менә бу икенче төрдәге нәзер турында пәйгамбәребезнең бер хәдисе бар. Ул анда: «Нәзерне тыям. Ул тәкъдирдән язмышны үзгәртми. Ул фәкать саран кешедән әйберен чыгара», – ди. Ягъни монда шуны аңларга кирәк: Аллаһы Тәгалә баланы армиядән син нәзер әйткәнгә күрә генә исән-сау кайтарамый. Нәзернең моңа бернинди катнашы юк. Юкса, кайбер кеше нәзер әйтсәм, ул әйбер була, әйтмәсәм, булмый, дип уйлап ялгыша. Кеше тормышында нәрсәнендер булуын теләсә, дога кылсын, Аллаһы Тәгаләдән сорасын. Яки нәзер әйткәнче, корбаныңны болай гына чал, сәдакаңны болай гына бир. Аларны ниндидер шартка бәйләмә. Шул очракта гына ул дөрес була. «Я Раббым, улым-исән сау кайтсын», – дип, Аллаһы Тәгаләдән сорарга кирәк.

Кеше үзен нәрсәдән дә булса тыю өчен дә нәзер әйтергә мөмкин. Әйтик, тәмәке тартуын ташлый алмый азапланган кеше: «Әгәр тагын тәмәке тартсам, өч көн ураза тотам», – дип нәзер әйтергә мөмкин. Бу нәзернең өченче төре була.

:: Кеше әйткән нәзерен үти алмаса, ни эшләргә? Бу аңа гөнаһ булып языламы?

– Бу сүзендә тора алмый икән, вәгъдәсен үтәп, ул өч көн ураза тота яки кәффарәт кыла, ягъни кылган хаталар һәм гөнаһлар өчен, Аллаһның ярлыкавына ирешү нияте белән билгеле бер эш башкара. Төгәлрәк әйтсәк, нәзерен үти алмаса, ул ун мескенне ашата яки ун мескенне киендерә, яки кол азат итә. Хәзерге вакытта коллар юк. Мескеннәрне киендерергә, ашатырга акчасы булмаса, ул өч көн рәттән ураза тотарга тиеш. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: «Нәзерләр әйткән, әмма үтәмәгәннәргә Аллаһы белән очрашканчыга кадәр монафикълык сыйфаты языла», – диде.

:: Димәк, кеше бу урынга башка гомердә дә аяк басмаячакмын, дип нәзер әйтеп, билгеле бер вакыттан кабат шунда барса, ул да шуларны эшләргә тиеш булачак?

– Әйе, бу очракта да шушы ук таләпләр үтәлергә тиеш.



unsplash.com

:: Кайчак көндәлек генә: «Фәлән эшне эшләр идем», – дип уйлап куясың. Бу шулай ук нәзер әйтү саналамы?

– Нәзер ул – тел белән әйтү. Көндәлек бер нәрсәне эшләргә уйлау ул әле нәзер түгел. «Аллаһ ризалыгы өчен шуны эшлим», – дип тел белән әйткән сүз генә нәзер булып санала.

:: Әйткән нәзерне үтәүнең төгәл вакыты бармы? Ул вакыт ягъннан чикләнгәнме?

– Әгәр кеше нәрсәне дә булса гомер буе эшләргә нәзер әйткән икән, ул аны гомер буе эшләргә тиеш була. Шуңа күрә нәзер – бик хәтәр әйбер.

:: Әйткән нәзереңне онытсаң, ни эшләргә?

– Бу очракта да кеше кәффарәт кылырга тиеш була. Ягъни ул ун мескенне ашата яки ун мескенне киендерә, яки кол азат итә. Боларны эшләргә мөмкинлеге булмаса, ул өч көн рәттән ураза тотарга тиеш.

:: Нәзере булган кеше җан бирә алмыйча тилмерер, дигән фикер дә яши. Бу сүзләр дөреслеккә туры киләме?

– Бу сүзләрнең ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килүен әйтү кыен. Әмма әйткәнемчә, нәзер ул – бик хәтәр әйбер. Ул кеше тормышына, әлбәттә, тәэсир итәргә мөмкин. Чөнки нәзерне үтәмәгән саен, аңа гөнаһ язылып бара.

:: Кеше исән чакта әйткән нәзерен үтәп өлгерә алмаса, аның нәзере гаиләсе, туганнары өстенә каламы? Әллә һәркем үз нәзерен үзе үтәргә тиешме?

– Әгәр кеше исән чакта нәзерен үтәп өлгерә алмаган булса, моны аның малыннан туганнары эшли. Әгәр мәрхүм сәдака бирергә ниятләгән булса, аның мирасыннан сәдака бирелә. Корбан чалам, дип әйткән нәзере калган булса, аның малыннан корбан чалына.

КЕШЕЛӘР БЕЛӘН ҮЗ-ҮЗЕҢНЕ ТОТУ ӘДӘПЛӘРЕ

shutterstock.com

✓Бинага кергәч тә яисә бер төркем кеше белән очрашкач, иң элек сәлам бирергә, аннан соң башкаларга комачауламый торган урынга барып утырырга кирәк.

✓Кешеләргә түбәнсетеп караудан сакланырга кирәк. Югыйсә моның сине һәлакәткә илтүе бар, чөнки син әһәмият бирмәгән ул кешеләрнең синнән яхшырак һәм тәкъварак булу ихтималы бар. Бай кешеләр арасында булганда, аларга сокланып карау килешми, чөнки бу дөнья һәм дөньяда булган барлык нәрсә Аллаһы Тәгалә өчен бернинди кыйммәткә ия түгел.

✓Дөньяви әйберләргә зур әһәмият бирмәскә кирәк, югыйсә дөньяви байлыкка ия булып, Аллаһы Тәгалә каршында түбән булган кешеләрне дә өстен күрергә мәҗбүр буласың.

✓Әгәр кем дә булса берәрсенә ярдәм итсә яки аны мактаганнарын ишетсә, моның Аллаһы Тәгаләдән икәнен белергә һәм шунда ук Раббыңны мактау белән искә алырга ашыгырга, Аңа кешеләр кулына калудан сыенып дога кылырга кирәк. Әгәр кем дә булса берәүгә золым кылса, аның хакында начар сүз әйтсә, гайбәт таратса, аны үпкәләтерлек берәр нәрсә әйтсә, ул кешенең тәкъдирен Аллаһы Тәгаләгә тапшырырга һәм Аннан сезне дошманнарга әйләнүдән саклавын сорарга кирәк.

✓Аларны хөкем итү һәм тәнкыйтьләүдән тыелу дөресрәк, чөнки моннан бернинди дә файда булмаячак, киресенчә, дошманлыкларын гына арттырачак. Андый кешеләргә үпкәләүдән дә файда юк. Иң яхшысы – кешеләрнең шулай сөйләвенә сәбәп булган гөнаһларың өчен тәүбә итү, Аллаһы Тәгаләдән истигъфар сорау. Тәнкыйтьне тыңларга, ләкин буш сүзләргә игътибар итмәскә кирәк.

Йөгез, бер дога!

ТЕШ СЫЗЛАГАНДА УКЫЛА

«Аллаһүммәәзһиб гәнһү сүүә мә йәҗиду үә фәхшәһү би дагъуәтии нәбийикәль- мәкиинилъ-мүбәәраки гиндәк».

Мәгънәсе: «Аллаһым! Синең каршыңда мөбарәк һәм мөхтәрәм булган пәйгамбәреңнең догасы белән бу тешнең авыруын ал».

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Ләйсән САФИНА

РӨСТӘМ НАСЫЙБУЛЛИН: «ҮЗЕМЧӘ ЭШЛӘРГӘ ЯРАТАМ»

Сәхифәбезнең бүгенге кунагы – Халыкара конкурслар лауреаты, җырчы Рөстәм НАСЫЙБУЛЛИН. Күптән түгел 30 яшен тутырган җырчының нинди яңалыклары бар? Әллә репертуарын үзгәртергә уйлыймы? Ни өчен ул үзеннән олырак дуслар сайлый?

:: Ни хәл?
– Аллаһка шөкер. Күптән түгел 30 яшемне тутырдым, туган көнемдә концерт куйдым. Үз тавышым белән 29 җыр башкардым. Халык канәгать калды, дип уйлыйм. Концерттан соң уңай кайтавазлар килде. Соңгы айларда яңа җырлар иҗат иттек. Минем фамилиядәшем, «Сак-сок» беренче татар фолк-рок төркемен җитәкләгән Заһир абый Насыйбуллин репертуарыннан минем өчен үзгә юнәлештә булган берничә җыр алдым. Бөтен якка таба эшлибез хәзер. Башта миңа килешмәс бу, шырты-пырты җырлар дип әйтүче булыр, дип курыккан идем. Җырлап карыйк әле, халык ошата бит.

:: Сезнең репертуарыгызның күп өлешен патриотик җырлар алып тора. Бу нәрсәгә бәйле?
– Хат ташучыбыз Ризәлә Габдрахманова булмаса, дөнья бетәр төсле, – ди Яшел Үзән районындагы Тугай авылында яшәүче Мәдинә Шәмсиева. – Безнең авыл бик кечкенә, утызга якын хуҗалык бар. Нигездә минем кебек ялгыз өлкәннәр яши. Урындыкка басып, исәплегеч күрсәткечләрен язып алуы да кыен. Шөкер, бөтен авылга бер Ризәләбез бар. Күрше авылдагы почта бүлекчәсеннән газета-хатларны да, пенсияләрне дә алып кайта, коммуналь түләүләрне түли, счетчик күрсәткечләрен үзе тапшыра. Авылда кибет юк. Кирәкле азык-төлекне дә сумка тутырып почтальон ташый. Аңа рәхмәттән башка сүз юк.

Әле күптән түгел редакциягә шалтыратып, Чүпрәле районының Keче Чынлы авылында почта бүлекчәсе бөтенләйгә ябылуын, халык язылган газета-журналларны клуб тәрәзәсе төбендә калдырып китүләрен хәбәр иткәннәр иде. Халык гозерен бу эшне контрольдә тотучы җирле җитәкчелеккә җиткердек. Шөкер, авылдан шалтыратып, почта бүлекчәсе кабат эшли башлады, дип сөенечле хәбәр җиткерделәр.

– Почта бүлекчәсе ачылгач, газета-журналларга языла башладылар, – диде бирегә билгеләнгән яңа җитәкче Радик Ситдыйков. – Дөрес, әлегә почтальон юк, эзлибез. Газета-журналларны атнага өч тапкыр почта бүлекчәсенә алып киләләр. Халык шуннан килеп ала. Авылыбыз зур, безгә почта бүлекчәсеннән башка булмый, әлбәттә.

Республика күләмендәге вазгыятьне белергә теләп, республиканың төрле районнарында почта эшчәнлеге өчен җаваплы җитәкчеләргә дә шалтыратып карадык. Тик ачылып китеп сөйләшергә теләүче табылмады. Дөресрәге, журналистлар белән аралашу өчен, әлегә дә баягы, берләштерелгән үзәктән рөхсәт алырга кирәк, дип аңлаттылар. Үзара сөйләшкәндә, проблема булуын һәм аны үзләре дәрәҗәсендә хәл итәргә, басма матбугат укучыларны кыен хәлдә калдырмаска тырышуларын әйттеләр. Өметне өзмик.

ИШЕТЕРГӘ ТҮГЕЛ, КИЛЕШЕРГӘ

ЯШЬ БУЫННЫҢ ИХТЫЯҖЛАРЫ КАНӘГАТЬЛӘНДЕРЕЛӘМЕ?

«Ватаным Татарстан» редакциясе каршында оешкан «Туган тел» клубының чираттагы утырышы яшьләр һәм милли мохит темасына багышланды.

«Түгәрәк өстәл»дә Татарстан яшьләр эшләре министры **Ринат САДЫЙКОВ**, «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире **Гөлнара САБИРОВА**, «Кыстыбый tatar food» рестораннары челтәре генераль директоры **Азат НӘҖМЕТДИНОВ**, «Татарча casual» проекты җитәкчесе **Айгөл СИНГАТУЛЛИНА**, «Идел» журналы баш мөхәррире **Рәмзия ГАЛИМОВА**, «Сәләт» яшьләр үзәге директоры **Айгөл ГАБДРАХМАНОВА**, «Тиз уку» проекты авторы, ШАЯН ТВ алып баручысы, татар активисты **Мәликә ХӘЙРУЛЛА**, Теләче районындагы Баландыш авылы мәдәният йорты җитәкчесе **Илсаф ТИМЕРБАЙЕВ** катнашты. Укучылар игътибарына әлеге утырышта яңгыраган фикерләрне тәкъдим итәбез.

:: Әңгәмәне Яшьләр эшләре министрлыгыннан башлыйсы килә. Татар яшьләре белән нинди эшләр башкарыла?

Ринат САДЫЙКОВ:
– Әлбәттә, яшьләр өчен проектлар бар һәм алар эшли. Ике зур һәм сыйфатлы үзәгебез – «Сәләт» белән «Идел» бар. Алар үз форумнарын да уздыра, масштаблы проектларны тормышка ашыра. Хәзерге көндә министрлык төрле тармаклардагы иҗтимагый оешмалар һәм физик затларның проектлары өчен грантлар да бирә. Өченче ел инде иҗтимагый оешмалар өчен генә түгел, муниципаль учреждениеләр өчен дә конкурс үткәрәбез. Яңа идеяләр, проектлар бар икән, без аларны тыңларга әзер.

Айгөл ГАБДРАХМАНОВА:
– Минемчә, милли яшьләр, башкасы дип бүлгәләргә дә кирәкми. Яшьләр – барысы да яшьләр, барысы да безнеке. Һәркайсы барлык мөмкинлекләрдән файдалана ала. Һәрбер министрлыкта да яшьләргә карата аерым программалар бар. Шулардан да файдаланырга мөмкин. Монда яшьләрнең теләге һәм омтылышы да мөһим.

:: Сүз дә юк, яшьләр өчен дәүләт тарафыннан бик күп мөмкинлекләр тудырыла. Әмма без татар яшьләре турында сөйләшергә җыелдык. Милли үзаңны формалаштыру, милли мохит булдыру бурычы тора. Моның өчен аерым яшьләр, аерым проектлар кирәк.

Айгөл СИНГАТУЛЛИНА:
– 18–35 яшь – шундый рәхәт яшь. Хәзер инде җәмгыятькә дә мөнәсәбәт үзгәрә, фикерләү дә. Әмма үзем дә шул юлны узган кеше буларак әйтәм: проектларга ярдәм җитәрлек түгел. Дөресе шул. Эш башлаган мәлдә ничек акча эшләргә белмисең бит әле. Үзеңне күрсәтергә, бу грантка лаек булуыңны дәлилләргә кирәк.

Бәлки безгә милләткә, телгә файдалы булган, шул ук вакытта дотациягә яшәгән түгел, ә бизнес буларак яши алырдай проектларны үстерергә кирәктер? Бездә күпчелек проектлар дотациягә яши. Әлбәттә, уңыш казанганнары бар. Бизнес-проектлар булдырырга булышыйк. Башлангыч этапта аларга этәргеч кирәк. Аннары үз көннәрен үзләре күрәчәк.

Тел мәсьәләсе дә һәрвакыт актуаль кала. Шуны да әйтергә кирәк: татар телен өйрәтә торган онлайн мәктәпләр дә юк. Ник юк ул?

Ринат САДЫЙКОВ:
– Сезнеңчә, моңа ихтыяҗ зурмы? Бизнес нигә бу юнәлешкә алынмый?

Айгөл СИНГАТУЛЛИНА:
– Бу проблема белән үзем очрашканга, минем моңа ихтыяҗ туды. Ихтыяҗ, дибез инде без... Ә бит милли киемнәргә дә ихтыяҗ юк иде. Монда масштаб та мөһим. Мин физик затлар да эшли алырлык дәрәҗәдәге, 20, 30, 200 баланың ихтыяҗын канәгатьләндерерлек мәктәп турында әйтәм. Безнең әле анысы да юк.

Азат НӘҖМЕТДИНОВ:
– Беренчедән, шуны билгеләп үтәсе килә: хәзер глобализация чоры. Кечкенә нәрсәләрне зурлары йота бара. Хәтерләсәгез, элек таксистлар күп, һәркем үзенә эшли иде. Хәзер инде аларны берләштерделәр.

Үзгәрешләр тел мәсьәләсенә дә кагыла. Бер караганда, «әйе, бетә» дип тә утырырга, шул ук вакытта, мөмкинлектән файдаланып, булган энергияне дөрес юнәлешкә борып җибәрергә дә мөмкин. «Кыстыбый»ның милли мәдәниятка керткән өлеше турында әйткәндә, без, һич югы, кешеләрне өч телдә сәламлибез, ризыкларга татар сүзләрен кертәбез, татар көйләрен кушабыз. Безнең максат – татарчаны, миллилекне популярлаштыру, «модно» итү. Әтием Актаныштан, аның: «Без Казанда татарча сөйләшергә ояла идек», – дигәне бар. Аның заманында ничек булган! Бу Татарстан башкаласында! Ә ни өчен? «Стремно», «модно» түгел. Хәер, хәзер вазгыять үзгәрә. Әмма барыбер татар телен кәттә итү максаты булырга тиеш, аның кәттәләгән расларга кирәк. Бизнес ягыннан карасак, татарча кәттә бизнес-проектлар күп булырга тиеш дигән сүз. Безнең мондый мисаллар бар инде.

Татар телендә сөйләшү мөмкинлегеге булган мохит кирәк. Әйтик, мин татар телен мәчеттә, кайбер тапшыруларда, шушындый утырышларда гына кулланам, дисәм дә була. Мәҗбүри мохит булырга тиеш дип саныйм. Берләшү, очрашу, сөйләшү кирәк. Бизнеста бу нетворкинг дип атала. Ә бу юк. Утырып сөйләшкәч, күп нәрсә аңлашыла, элемтәләр барлыкка килә. Аерым булсак, әллә нәрсәгә ирешә алмабыз. Ә берләшсәк, синергия барлыкка килсә, нәрсәдер китереп чыгарырбыз төсле.

Айгөл ГАБДРАХМАНОВА:
– Бездә татарлык көчле инде. «Мин», «мин генә», «берәүне дә якын китермим», көнләшү... Безнең мәдәни кодыбызмы инде ул, канызыга сеңгән бу. Аны үзгәртергә кирәк. Моны яшьләрдән башласак яхшы. Берләшү, дөрестән дә, бик җитми.

:: Ә мондый берләштерү эше белән кем шөгыльләнергә тиеш, дип саныйсыз?

Азат НӘҖМЕТДИНОВ:
– Бу сорауны министрлыкка бирергә кирәктер.

Айгөл СИНГАТУЛЛИНА:
– Комиссия (Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе турында сүз бара – **Авт.**) кысасында нишләп әле Яшьләр комитеты юк? Олылар алар башкача уйлый, бөтенләй башкача фикерли бит.

Ринат САДЫЙКОВ:
– Бу бит начар түгел. Яшьләр үз проектларын аларга җиткерә һәм ярдәм таба.

Айгөл СИНГАТУЛЛИНА:
– Яшьләр өчен аерым, олыларга аерым берлек булырга тиеш. Алар икесе дә бер үк дәрәҗәдә булсын. Яшьләрне үстерергә, аларның фикерен ишетергә генә түгел, аларга ышанырга кирәк. Бәлки, яшьләр белән бер тигезлектә булып, «мин сине ишетәм» дип кенә түгел, «яхшы, эшлик» дигән башка төрле мөнәсәбәттә булыргадыр? Билгеле, олылар күбрәк белә, аларда тәҗрибә. Ә яшьләр әле тәвәккәллеккә хирыс.

Азат НӘҖМЕТДИНОВ:
– Зур масштабтагы татар фестивале оештырырга кирәк. Сабан туе белән бутамыйк! Бу фестиваль бик масштаблы, кәттә булырга тиеш. Хәтта ки Россия күләмендә генә дә түгел. Бәлки, Азия, гарәп, БДБ илләренең дә игътибарын җәлеп итәргә. Бу фестивальдә кием дә, мультфильмнар да, фильмнар, ризык та булырга тиеш.

:: Без һаман да шәһәр яшьләре турында гына сөйлибез. Авыл яшьләре күзлегеннән караганда, яшьләргә нәрсә җитми?

Илсаф ТИМЕРБАЙЕВ:
– Күпләр килешер, татар теле саклана торган төп урын – авыл. Авылга кайт-

кан студентлар, шәһәр балалары да татарча сөйләшәләр. Ләкин авылларда яшьләрне җәлеп итеп торырга мөмкинлекләр аз. Мисал өчен, җомга көнне яшьләр авылга кайта да кая бара? Кич белән мәдәният йортына чыга һәм, кызганыч, берни эшли алмый. Авыллар да шәһәрчә яши, дисәк тә, мөмкинлекләр ягыннан алар барыбер арттарак. Мисал өчен, чаралар уздырсак та, төп басымны фольклорга бирәбез, өлкәннәр өчен дип уткәрәбез. Хәтта ки яшьләр яратып йөри торган дискотеканы да оештыра алмыйбыз. Татар телендә узса да, башкача узса да, рөхсәт сорарга кирәк. Әмма дискотекалар ярамый, дигән сүз бар. Ниндидер бер стереотип яши: яшьләр бергә җыелган җирдә тәртипсезлек була, имеш.

Әмма проблема яшьләрнең үзендә дә бар. Аларда кызыксыну юк. Аларга берәр ни тәкъдим итсәң: «Миңа кирәкме? Миңа нәрсәгә бу?» дигән җавап килә. Клубта без аларга туп уйнау белән «Күңелле стартлар» гына тәкъдим итә алабыз.

Мәликә ХӘЙРУЛЛА:
– Фән өчен җан әрни әле. Без һаман күңел ачуга кайтып калабыз, бизнес, дибез. Ышанмассыз, әмма яшьләр һаман да фән белән кызыксына. Әмма фәнне үстерергә мөмкинлекләр юк. Грантларны да күңел ачу, бизнес проектларына гына бирәләр. Белем арттыру проектларына грантлар бирелми. Ә кайвакыт андый проекты булган кешеләр идея өчен генә дә эшләргә әзер бит! Алар хәтта үзләренә акча да сорамаска мөмкин.

Актуаль нәрсәләрне дә татарчалаштырып була. Без бит татар телендә психология турында да сөйләшмибез! Тел ул кайчан үсә? Аңа ихтыяҗ булганда, кеше шул тирәлектә бу телдә сөйләшергә мәҗбүр булганда. Нишләп бездә татарча психологлар булмаска тиеш? Татар телендә курслар узмаска тиеш?

Күңел ачу проектлары бар, алар популяр. «Гыйлем» проекты бар иде. Нишләп сүрелде? Идея белән берничә ел гына эшләп була шул ул...

Айгөл ГАБДРАХМАНОВА:
– «Саклау» сүзенә әйләнәбез дә кайтабыз. «Үстерү» сүзе бөтенләй ишетелми. Тел үссен өчен, ул IT тармакта, цифрда, санакта, телефонда булырга тиеш. Тәрҗемә белән генә булмый. Әмма моңа вакыт кирәк, билгеле. Безнең дәвердә генә булырлык эш тә түгелдер бу...

Рәмзия ГАЛИМОВА:
– Без күнегелгән аудиториягә эшләргә ияләшкән. Татарча белә һәм сөйләшә алар. Әмма бар шундый кешеләр: әйтик, ул татар, әмма русча сөйләшә. Ә бәлки ул, авылга кайткач, татарча сөйләшәдер? Минемчә, без андый кешене җәлеп итә алабыз. Без журналны чыгарганда да шуны күздә тотабыз. Андый кеше дә безнең журналны алсын, укысын, кызыксын өчен тырышырга кирәк. Иң беренче чиратта кызыксыну уятырга кирәк.

:: Сезнеңчә, татар ул – татарча сөйләшкән кешеме, әллә инде милли проект булдырып, милләт өчен җан атып йөргән, әмма татар телен бик үк камил белмәгән кешеме?

Айгөл СИНГАТУЛЛИНА:
– Минем клиентларым – төрле шәһәр, төбәк кешеләре. Миңа Аллалар, Екатериналар, Татьяналар яза. Әйтик, Аллага Германиягә кием әзерлибез, Татьянага Алтайга җибәрдек. Алар татарча белми. Әмма аларның милли күлмәк киясе килә. Мин шаккатам моңа! Мин андый кешене ничек татар түгел дип әйтим?

Мәликә ХӘЙРУЛЛА:
– «Белмәү гаеп түгел, белергә теләмәү гаеп» дигән әйтем безнең халыкта юкка гына яшәми. Кеше телне һәрчак өйрәнә ала. Бу бит проблема түгел. Безнең максат – телебезне өйрәнеп, әнә шундый кызыксынучан кешеләргә өйрәтү.

Илсаф ТИМЕРБАЙЕВ:
– Хәзер барыбыз да кесә телефонында, барысын да белеп торабыз кебек. Сүз дә юк, Казанда төрле кызыклы чаралар үткәрелеп торадыр. Әмма, кызганыч, алар турында мәгълүмат аз. Андый чараларга авылдагылар да бик теләп килер иде. Белсә, әлбәттә.

Кызыксындыруга килгәндә, интернет мәйданчыкларында татарча контент бик аз. Юк диярлек. Мин мәдәният өлкәсендә эшләгәч, кызыклы интервьюлар тыңларга яратам. Әмма алар бертөрле, мин инде сорауларын да, җавапларын да алдан беләм. Бу сорауны күтәрсәң, ихтыяҗ юк, диячәкләр, аннан финанс мәсьәләсе килеп басачак.

Рәмзия ГАЛИМОВА:
– Матбугатта да, телевидениедә дә, интернетта да яшьләрне кызыксындырырдай кешеләрне күрсәтсәк, алар турында сөйләсәк яхшы булыр иде.

:: Яшьләр милли мәсьәләләрдән читтә калмасын өчен нишләргә? Бу җәһәттән нәрсә таяну ноктасы булырга мөмкин?

Рәмзия ГАЛИМОВА:
– Иң мөһиме: бирешмәскә. Көндәшлек булмасын иде. Без һаман саклыйбыз дибез, ә безгә үстерергә кирәк. Ә моның өчен бердәм булу җитми. Сыйфатка игътибар биреп, алга барырга.

Азат НӘҖМЕТДИНОВ:
– Маркетингта «кое» дигән принцип бар. Кайда су бар, шунда казыйсың. Казый башлагач, су барлыкка килә. Кемдер су чыккач та казый, кемдер читкәрәк китеп, яңа кое казый.

Безгә дә үсеш нокталарын билгеләргә кирәк. Шуннан чыгып, стратегия барлыкка киләчәк. Без, бер генә нокта табып, бернәрсәгә дә ирешмибез. Без саклауга энергиябезнең 80 процентын бирәбез. Үсештә булган нәрсәләргә түгел бу. Әйтик, кием-салым, ризык, аякка басып килүче кино. Аларга кызыксыну да, ихтыяҗ да бар.

Без миллионнарны телне саклауга тотып, үсештә булганнарын югалтырга мөмкинбез. Ничек кенә авыр булмасын, тел үлә бара. Глобаль карасаң, шуңа таба барабыз. 3–4 буыннан тел җәһәтеннән күп нәрсәләр югалачак.

Илсаф ТИМЕРБАЙЕВ:
– Яшьләргә бәйле проектларны яктырту җитми. Без күз алдында ни тора, шуны карарга күнеккән бит. Татарчаларын эзләргә, табарга, сайларга кирәк. Әле тапсаң! Шулай ук тарихны да, татар халкы турында да яшьләргә күрсәтү җитми.

Мәликә ХӘЙРУЛЛА:
– Тәбрис Яруллинның (Бөтендөнья татар яшьләре форумының элеккеге рәисе, хәзерге вакытта Милли китапханә директоры урынбасары. – **Авт.**) лозунгы белән яшибез: татарчаны популярлаштырабыз, популярны татарчалаштырабыз. Шулай булсын, дәвам итсен. Моңа көч түгәбез. Әхлакны да онытмасак иде. Ул – таянычыбыз.

Айгөл СИНГАТУЛЛИНА:
– Без сөйләшергә яратабыз инде. Ә бит иң мөһиме – монда сөйләшү генә түгел, ә аннан соң булган нәтиҗәләр.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.
Фото: Ләйсән САФИНА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Фәнне һәм мәгарифне үстерүгә, югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры **Габдуллаҗанов** Эдвард Юныс улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Социалистик Хезмәт Герое **Габдрахманова** Стэлла Зәки кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Техник фәннәр докторы, «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фән һәм коммерцияләштерү буенча проректоры **Ившин** Игорь Владимировичка, техник фәннәр докторы, «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең архитектура һәм агач эшләнмәләр дизайны кафедрасы мөдире **Сафин** Руслан Рушан улына, биология фәннәре докторы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Фундаменталь медицина һәм биология институтының Биология югары мәктәбе Биология һәм педагогик белем үзәге кеше һәм хайваннар физиологиясе кафедрасы мөдире **Ситдыйкова** Гүзәл Фәрит кызына, филология фәннәре докторы, «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт бюджет фәнни учреждениесе «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты» аерымланган структур бүлекчәсенең халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре **Мөхәммәтҗанова** Лилия Хатыйп кызына **«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Оборона министрлыгының «Казанның Жуков орденлы Кызыл байраклы югары танк команда училищесы» федераль дәүләт казна югары хәрби белем бирү мәгариф учреждениесенең гаскәрләрдә (көчләрдә) хәрби-сәяси эш кафедрасы доценты **Шуралев** Сергей Геннадьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе полиция башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Тәхавиев** Азат Илсур улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәләренең эшчәнлеген оештыру идарәсе полиция участок уполномоченныйлары эшчәнлеген оештыру бүлеге башлыгы урынбасары, полиция подполковнигы **Чумарин** Сергей Янузывичка **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

СЕЗ ИҢ ТҮЗЕМ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!

КОМИССИЯ УКЫТУЧЫНЫҢ ДӘРӘҖӘСЕН КҮТӘРЕРМЕ?

Укытучыга сүз әйтәсе түгел! Мәктәпләрдә махсус комиссия төзеп, аларның хокукларын якларга, абруен күтәрергә җыеналар. Россия мәгърифәт министры Сергей Кравцов әнә шундый яңалык җиткерде. Кайчан төзелеп, аңа кемнәр керәсе әлегә билгесез. Файдасы булырмы? Фикерләр төрле

Илдар Мөхәммәтҗанов

Карга күзен карга чукымый

Моннан берничә ел элек Мөнирә Садыйкова мәктәптә сирәк була торган адымга барды. Лаеш районындагы Столбище мәктәбенең элеккеге татар теле һәм әдәбияты укытучысы кыскартылган өч дәрес өчен директорны судка бирде. Нәтиҗәдә район мәхкәмәсе татар теле сәгатьләрен кире кайтарды. Хәзер Мөнирә Садыйкова балаларны математикага өйрәтә.

– Гадәттә гауганы зурга җибәрмәгәнне яраталар. Ә мин хокукларымны яхшы беләм. Мин эшләгән мәктәптә җитәкчелек белән профсоюз бер сүздә иде. Алар барыбер үзләренчә хәл итә. Карга күзен карга чукымый. Аңлатып карадым, нәтиҗәсе булмагач, Хезмәт инспекциясенә мөрәҗәгать иттем. Иң ышанычлысы – суд, – ди үз хокуклары өчен көрәшкән Мөнирә Садыйкова.

Аның фикеренчә, федераль министр әйткән комиссияләр оеша калса, андагы белгечләр гадел һәм белемле булырга тиеш. Ялагайлар керә икән, оештырудан мәгънә юк. «Минем әле аттестация үтәсем бар», «Мактау кәгазе алмаган», «Өстәмә сәгатьләр дә кирәк», – дип уйлаган, агымга каршы бара алмаган укытучыларны анда кертергә ярамый.

Кемнән яклыйлар?

Мәгърифәт министры Сергей Кравцов белдергәнчә, мондый комиссияләр мәктәпләрдә килеп чыккан бәхәсле очракларны гадел хәл итү өчен кирәк.

Ниятләре изге. Әмма яңалыгы нидән гыйбарәт? Ник дигәндә, әле октябрь ахырында гына Дәүләт Думасына кертелгән закон проектында да укытучының абруен күтәрү турында сүз бара.

Документта, белем генә түгел, тәрбиягә карата да игътибарны арттырырга кирәк, диелә. Шулай ук әлеге проект мәктәп хезмәткәрләренең хокукларын бозуга, аларга карата физик һәм психик яктан көч куллануга юл куймауны да күздә тота.

Кыскасы, бу хакта еш һәм күптән сөйлибез, әмма аңа карап кына үзгәрешләр бармы?

– Яңа комиссия хәзергеләреннән кайсы ягы белән аерыла? Анда кемнәр керә? Ул гауга лы очракларны хәл итәчәкме, әллә һөнәргә бәйле бәхәсләрнеме? Шуларны белмичә, нинди дер фикер әйтү авыр, әлбәттә. Мәктәпләрдә аңлашылмаучанлыклар туганда, җайга салу тәртибе бар. Директор андый комиссияне булдыра ала, – ди Казандагы халыкара мәктәп директоры, депутат Нияз Гафиятуллин.

Чаллы мәгариф идарәсе башлыгы Рөстәм Хуҗин фикеренчә, укытучының дәрәҗәсе бар. Аны бары сакларга гына кирәк.

– Әмма үзегез беләсез, төрле хәлләр була бит, – ди Рөстәм Хуҗин. – Укыту һәм тәрбия – әти-әни белән бергә алып барыла торган эш. Мәктәп, әти-әни карашы аерым була алмый. Бу очракта нәтиҗәгә ирешү мөмкин түгел. Әти-әнинең дә, мәктәпнең дә максаты бер: белемле һәм тәртипле бала тәрбияләү.

Алабуганың 1 нче гимназиясе укытучысы Айгөл Һадиуллина, укытучыларны әти-әниләрдән яклау өчен комиссия кирәк, дип саный. Җәмәгать, кая барып җиттек без? Шулай да Айгөл ханымның сүзләренә игътибар итик әле.

– Мәктәп җитәкчелегеннән якларга профсоюзлар бар. Ә менә укучылардан яклау өчен әти-әниләрдән торган комиссияләр кирәк. Күптән түгел бездә шундый хәл булды. Бер әни баласының укый алмавын танымыйча, укытучыга бик авыр сүзләр әйткән. «Сез хаклы түгел, прокуратурага барам», – дип янаган. Шуннан соң укытучы хастаханәгә эләкте. Мәктәп җитәкчелеге яклый алмагач, ул эштән китте. Әлеге сыйныфның дәресләрен башка укытучыларга бүлеп бирделәр. Укытучы таба алырлармы, белмим. Андый гауга лы сыйныфка киләм дип торучылар да булмас әле. Комиссия укытучыларны шундый мәсьәләләрдә якласа, яхшы булыр иде, – ди география укытучысы Айгөл Һадиуллина.

Бары бер нәрсә генә кирәк!

Татарстан Мәгариф хезмәткәрләре профсоюз оешмасының хезмәт хокуклары буенча баш инспекторы Диләрә Бургуева фикеренчә, иң элек хезмәт хакларын күтәрергә кирәк.

– Мондый комиссияләр, нигезләмә язып, аны сайтка элә өчен кирәкме? Әллә формаль рәвештә кемнедер кертергә яки сан өчен берничә чара уздырыргамы? Кемгә кирәк ул? Комиссиядән комиссия төземәсеннәр, хисаптан – хисап, чарадан чара булдырмасыннар инде. Бу бит – башбаштаклык. Боларны ишетү оят, – ди Диләрә Бургуева. – Мондый тәкъдим белән чыгучылар урыннардагы хәлне белми, димәк. Моны хәтта кимсетү кебек кабул итәм.

Бездә комиссияләр җитәрлек. Һәр оешмада профсоюз вәкилләре эшли. Бу өлкәдә 20 ел хезмәт куям инде. Көн саен укытучыларның моңзарларын тыңлыйбыз, шикаятьләр кабул итәбез, аңлатабыз, хәл итәргә тырышабыз.

Диләрә Бургуева әйтүенчә, Укытучылар һәм остазлар елында укытучылар бары бер нәрсәне көтте. Аларга парк-скверлар, музей һәм бәйрәмнәр дә түгел, лаеклы хезмәт хакы кирәк. Гыйнвар аенда оклад бер тапкыр күтәрелгән. Шуннан бирле бер тиен дә артмаган. 40–48 мең сум хезмәт хакын тәҗрибәле белгечләр, «выслуга» өчен өстәмәләр түләнгән, югары квалификацияле категориягә ия педагоглар гына ала. Бер ставкага эшләүчеләрнеке 22 мең сумга да җитми. Һөнәри, федераль стандартлар бердәм, белем күтәрүгә таләпләр бердәм. Ә ни өчен хезмәт хакы алай түгел?

– Тәҗрибәмдә атнага 42–46шар сәгать укытучыларны күрдем. Монда нинди сыйфатлы белем турында сүз булырга мөмкин? Башкала бакчаларында тәрбияче, кече тәрбияче, пешекчеләр җитми. Мөдирләр еш кына үзләре плитә янына басарга мәҗбүр. Ә авылларда киресенчә, балалар саны аз булгач, укытучының сәгатьләре аз. Шулай булгач, акчасы да күп түгел. Тәрбиячеләрнең хезмәт хакы – 25–28 мең сум. Лаеклы түләнмәгәч, әлбәттә, укытучы халкы эштән китәргә мәҗбүр. Вазгыятьне матур итеп күрсәтәләр. Әмма кадрларга бәйле вазгыятьнең дөресен беркемнең дә күрсәткәне юк. Бу проблема белән берәү дә шөгыльләнми, – ди белгеч.

Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ, «ВТ» журналисты:

– Ниндидер комиссия белән кемнеңдер абруен күтәреп буладыр дип уйламыйм. Бездә абруйны кесә калынлыгы белән үлчиләр бит хәзер. Аз хезмәт хакына эшләүчегә кимсетеп карыйлар. Балаларның һәм әти-әниләрнең укытучыга мөнәсәбәтендә дә чагыла ул. Педагогик вузларга балдыксызлар кереп тулуга да тәэсир итә. Алардан абруйлы укытучы ыга алмый инде. Мин үзем мәктәптә эшләгән елларда Ташкичү мәктәбе укытучыларының абруе югары иде. Бездә конфликтлар да юк иде, коллективның яртысы ирләрдән тора, арада белеме белән дә, алтын кулы белән дә дәрәҗә яулаучылар күп иде. Шуңа районда иң югары нәтиҗәгә ирештек. Ул коллективтан аз кеше калды инде мәктәптә. Укытучының абруе җитәкчеләрнең аңа мөнәсәбәтенә дә бәйле. Йомышчы малай итеп карыйлар икән, дәрәҗә була алмый.

Рәшид НӘҖМЕТДИНОВ, укытучы-адвокат:

– Мин авыл мәктәбендә технология укытам, шул ук вакытта Казанда юридик оешмада эшлим. Безгә укытучылар да, укучылар да мөрәҗәгать итә. Мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы бар. Ул теләсә кайсы сораулар туганда булышырга тиеш. Прокуратура, Тикшерү комитеты… Яклаучы органнар болай да күп. Комиссия төзүгә караганда, мәктәп сыйныфларында видеокамералар урнаштыру яхшырак. Бу очракта гаугалар да бетәр иде. Укытучы белән укучы арасында бәхәсләр туганда, укытучы үзенең дөреслеген ничек дәлилли ала? Әйтик, бала дәрестә сүгенде, ди. Укучы: «Юк, мин сүгенмәдем», – диячәк. Бу очракта видеоязма дәлил булып тора ала. Бала укытучыны телефонына төшереп, интернетка да куярга теләмәс.

Әгәр укытучы үз хокукларын белмәсә, тагын 100 комиссия төзесәң дә, файда юк. Шул ягы да бар: укытучы анда мөрәҗәгать итәргә куркачак.

АЛЬБИНА ФАЗЛЫЕВА:
«БАШТА ҮЗЕҢ ЯРАТ!»

Балтач районының Бөрбаш авылында яшәүче блогер Альбина Фазлыева – төп йортта килен булу өстенә, 4 бала әнисе дә әле. Үз кием коллекциясен булдырып, бер ел эчендә өч кибет ачкан ханым да ул. Аның матур киемнәрен республикада гына түгел, хәтта чит төбәкләрдә дә яратып кияләр.

Авылда яшәп, шәһәрчә тормыш алып баручы, күп кенә яшь киленнәргә үрнәк итеп куярлык бу ханымга сокланмаган кеше юк.

– Тормышта яхшы гамәлләр кылырга, матур итеп яшәргә кирәк. Гомер бик тиз узып китә, – дип башлады сүзен Альбина. – Әти-әнием кечкенәдән безне дөрес тәрбияләде. Әтием һәрвакыт кешелеклелек сыйфатына өстенлек бирде. Өстәл янына утыргач, гел бу хакта аңлатырлар, уртага салып сөйләшер идек. Олыларга карата хөрмәткә дә гаиләмдә өйрәндем. Бездә тәртип шундый иде: дәү әни табын янына утырмаса, ризыкка тотынмыйбыз. Ул утырып, бисмилласын әйтеп, ризыкка үрелгәч кенә ашарга ярый. Бик дөрес тәрбия алымы булган икән, дим мин моны. Ә бүген карагыз сез: кешеләр ничек үзгәрде, үзеңне яратырга, чикләрне сакларга кирәк, диләр. Кеше болай да беренче чиратта үзен уйлый бит инде ул. Үзеңне тагын ничек саклап була икән?

Альбинаны иргә хезмәт итүгә, әти-әнигә булган мөнәсәбәт тә борчый. Күпләрнең, без ата-анага бер нәрсә дә тиеш түгел, диюләре дә гаҗәпкә калдыра аны. Әти-әнинең хәер-догасын алып калырга тырышырга кирәк, ди ул.

– Мин үземнең социаль челтәрдәге сәхифәләремдә нәкъ менә шул хакта сөйләргә булдым. Әти-әнигә, каенана-каенатага, балаларыңа карата кешелекле булып, һәр туган таң өчен Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтеп уяныйк. Халык бу сүзләрне кабул итмәс, дип борчылган идем. Баксаң, минем язылучыларым Аллаһка таба атлап килүчеләр икән. Елап карыйбыз, рәхмәт сезгә, дип тә язучылар күп. Мин кешеләрнең мөһим әйберләр турында уйлануларын телим, – ди Альбина. – Монда бардым, моны ашадым, монда кердем, дип кешеләрнең кадерле вакытын мәгънәсез әйберләргә сарыф итәсем килми.

Альбинаның Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәтнең килене икәнен белмәүче сирәктер. Шундый күркәм гаиләдә килен булу җиңел түгелдер. Бу хакта да сораштык.

– Тормышта яшьләр ягыннан да, олылар ягыннан да сабырлык булса, яшәү җиңелрәк дип уйлыйм. Өлкәннәрнең үз гадәтләре була. Аларны аңлап кабул итәргә тырышырга кирәк. Безнең әти белән әни – шулкадәр сабыр кешеләр. Беркайчан да безнең эшкә катышмыйлар. Кирәк чакта киңәшләрен генә бирәләр, – ди Альбина. – Тормышта бер-береңә юл кую, кайчакта дошмәни калу да хәерле. Хәдистә дә әйтелгән бит: кызып киткәндә, басып торсаң, утыр, утырып торсаң, ятып тор. Ятып та, ачуың басылмаса, тәһарәт ал. Әгәр шулай да ачуың бетмәсә, ике рәкәгать намаз укы, диелә. Үз-үзеңне тыю кирәк. Кайчак икенче көнне бу хәлләр бөтенләй вак нәрсәләр булып тоела. Вакыт узгач, ярый әле берни дәшмәдем, дип шөкер дә итәсең әле. Безнең өйдә әти дә, әни дә, Алмаз да, мин дә бик сабыр. Яшәгән саен бер-беребезгә хөрмәт арта.

Дүрт бала тәрбияләү өстенә өч кибет тә тотасы бит әле. Милли күлмәкләрнең барысын да Альбина өлгесе буенча тегәләр. Аларны кешегә күрсәтү, кибетләргә сатып алучылар җәлеп итү эше дә бар. Альбина гел яңа идеяләр белән яши. Әмма алдан кычкырган кукенең башы авырта, ди. Ә теләкләрен ишермиләр: мөселман хатын-кызларын зәвыклы итеп киендерәселәре килә.

– Кибет эшләрен ирем белән алып барабыз. Алмаз бик тә ярдәм итә. Әти белән әни янында яшәмәсәк, бу кадәр эшләр башкарып булмас иде. Тыштагы эшләрне әни белән ирем башкара. Минем мал караганым юк. Бакча эшләре – Җәлил әти өстендә. Без аңа булышабыз гына, – ди Альбина Фазлыева.

Балалар тәрбияләүдә ярдәм иткәннәре өчен, каенанасы белән каенатасына бик рәхмәтле Альбина. Алар тарафыннан оныкларга игътибар зур булуына сөенә. Балаларының әби-бабай назында үсүен теләгән дә инде ул. «Кичләрен бергәләп сөйләшү дә – зур тәрбия», – ди.

– Балаларыбыз төп йортта үсүләре белән бәхетле. Алар өлкәннәргә булган мөнәсәбәтне күреп үсә. Олыларга ярдәм итәргә кирәген дә беләләр. Хәтта ничек сөйләшәсен белү дә кирәк. Олы кеше гел үзенә әйтеп йөргәнне ярата. Әби белән үскән бала идем бит мин дә. Хәзер оныкларга әби-бабай тәрбиясе җитми. Олыларга карата хөрмәт күрсәтергә кирәклеген дә әйтеп үстерүче ата-ана сирәк. Өлкәннәр белән исәнләшергә кирәклеген белмәгән балалар да бар бит, – ди Альбина.

Тормышта нинди генә яхшылык эшләсәң дә, аның әҗере барыбер сиңа була. Альбина Фазлыева шул фикердә. Әти-әнигә күрсәткән игелек, туганнар арасындагы яхшы мөнәсәбәт – боларның барысының да сәвабы үзеңә, киләчәктә җимешләрен үзебез татыячакбыз, ди ул.

– Сине яратуларын теләсәң, башта үзең ярат. Туганнар белән араны көйләргә кирәк. Син яхшы энергияңне кешеләргә никадәр күбрәк бирәсең, ул сиңа шулкадәр күбрәк булып әйләнеп кайтачак, – ди ул. – Хәер-дога дигәне дә бар бит әле. Ул – шулкадәр зур нигъмәт. Кеше аны кулга тотып булмагач, күз белән күрмәгәч, бик аңламый. Үрнәк булып, балаларга яхшы тәрбия биреп, матур итеп яшәргә кирәк. Булдыра торган эш бит.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

Икесенә – бер язмыш

Казанда яшәүче игезәк егетләр Артур белән Альбертка ярдәм кирәк. Әниләре Динара аларны 17 ел буена яннарыннан да китмичә тәрбияли. Малайларның икесендә дә бер үк язмыш: табиблар аларга ДЦП диагнозы куйган, икесе дә йөри алмый, икесендә дә бер үк сызлану.

– Улларымның гомер буе авыру булулары миңа бер сынаудыр инде. Икесе дә көн саен минем ярдәмемә мохтаҗ булгач, өченче баланы алып кайтуны уйламадык та, – ди 39 яшьлек Динара. – Сабыйларым тугач та, безне башка хастаханәгә җибәрделәр. Андагылар дөрес диагноз куймаган икән. Без инде аларга ышандык, биргән даруларын да эчерттек, алар кушканча дәваладык. Шулай итеп, баш миенә дә зыян килгән. Альберт авыр сөйләшә. Артур исә барысын да ачык итеп әйтә.

Игезәкләр бер-берсе өчен янып яши. Артур белән Альберт арасында да шундый мөнәсәбәт. Аеруча Артуры сыңарын ташламый. Егылса, торырга ярдәм итә, әнисе буш булмаганда, ашата да. Малайлар бик тиз үсә. Әтиләренә охшап, озын буйлы буласылар икән. Динара үзе кечкенә генә булса да, балаларын йөртер өчен көч таба әле.

– Кечкенәрәк чакта хәйрия фондлары ярдәм иткәли иде. Бераз үсә төшкәч, алар да булыша алмады. Андый фондлар күбрәк кечкенәләргә ярдәм итә. Әле ярый, ирем эшли. Гаиләне алып бару – аның җилкәсендә. Улларымның пенсия акчалары да ярап куя. Мөмкинлекләре чикле булса да, гел каядыр барасылары килә аларның. Үземә охшаганнар, тик утыра белмиләр. Ә миңа йөртү кыен. Шулай булса да, җаен таптым, арбаларны тоташтыру өчен махсус җайланма сатып алдым, – ди Динара. – Моңа кадәр кешедән акча сорарга оялa идем. Якыннарым булышты, улларымны карашырга әле дә каенанам ярдәм итә. Быел ипотекага фатир алдык. Эш урыныннан бирелгән бүлмәдә улларыбыз белән 16 ел яшәдек. Үзләренеке булсын, дидек. Инвалид балалар булса да, аларга бернинди ташлама юк.

Малайлар үскән саен, өянәкләре ешая икән. Әгәр вакытында дәваламасаң, сызланулар артырга да мөмкин. Хәтта сөякләре бөкрәеп, эчкә керү куркынычы бар. Әниләре әнә шуннан курка да инде. Улларының интегүләрен теләми.

– Үзем генә физик күнегүләрне ясата алмыйм, массаж да бик кирәк. Әле бит бөтен җирдә дә безнең кебекләрне кабул итәбез дип тормыйлар. Кайдадыр дәвалану бар, яшәү өчен фатир арендалап тору кирәк. Шуңа күрә без яшәп дәвалана торган үзәк таптык, – ди Динара. – Балаларымны дәвалар өчен, чит кешеләрдән ярдәм сорамыйча булдыра алмадым. Хәлебезгә керсәгез иде!

Динара Шамил кызы Мостафина исемендәге 2202 2009 6371 4819 Саклык банкы, 5536 9139 7657 7417 Тинькофф банкы карталары 89179071427 телефон номерына беркетелгән.

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

П2435 >>
571 сум 98 тиен
(җомга)

П2409 >>
1255 сум 86 тиен
(сиш., чәрш., җомга)

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана. 23 ноябрьдә уйнатылачак бүләк – **АЛЬБИНА ФАЗЛЫЕВАдан ЯУЛЫК**

Бу атна җиңүчесе – Казан шәһәреннән Заһидуллина Мөнәвәрә. Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуыгызны үтенәбез!

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акциянe оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Реклама 16+



Әз-мәз мәзәк

Элек 50 яшьлек кешеләр бик олы күренә иде. Хәзер бик алай күренми, әйеме?

***

Элеккеге фильмнарны еламый карап булмый иде. Хәзерге фильмнарны карагнда да елыйсың. Сыйфатыннан.

***

Юл чатында малайга әби килеп эндәшә:
– Улым, юл аркылы чыгарга булыш әле.
– Хәзер, әбекәй, светофорда яшел ут янсын инде.
– Һи! Яшел ут янгач, мин үзем дә чыга алам.

***

Кеше олыгайган саен акыллылана дип уйлаучылар, телефонда ата-аналар чатларына керен карагыз.

***

– Ярар, һаман минем турында гына сөйләшмик. Синең турында да сөйләшик. Кем син?

Беләсең килсә...

1 Мәскәүдә нинди урам юк?
а) Ленин урамы;
б) Шмидт урамы;
в) Толстой урамы.

2 Алмаз Хәмзиннең телевизион тапшыруы ничек атала иде?
а) «Супер Алмаз»;
б) «Алмаз плюс»;
в) «Алмазда кунакта».

3 Автомобиль номерларында мондый регион юк:
а) 10RUS;
б) 20RUS;
в) 30RUS.

4 Буйга үсәр өчен, нәрсә ашарга кирәк?
а) кәбестә;
б) кыяр;
в) кишер.

Җаваплар:
1. а); 2. б); 3. б); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Сканворд җаваплары
Горизонталь: Марат, иллә, олы, яу, хат, Зәринә, зур, мур, ар, Ми, Әлки, Фәрхи, Тлюстен, ас, сәхнә, Азин, ни, тал, фа, ре, бай, чек, Казан, ярар, һинд, Зум, Сааб.
Вертикаль: Мөхәммәтҗан, баян, Уилл, Зифа, ротор, Кюри, Айваз, ал, ис, ру, тыз, фест, аһ, ияр, әнә, ЗиС, Луиза, хит, чана, Нурихан, аренда, әсәр, исәнлек.

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758. Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13584 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 354

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+